Раслыйм
МБМББУ "Катнаш төрдәге Балтач 1 нче балалар бакчасы" мөдире (Г.Х.Хайруллина)

2022 нче елның 31 августында № 90 приказы белән гамәлгә кертелде

2022 нче елның 29 августында №1 педагогик киңәшмәдә кабул ителде

Уртанчылар төркеменең (4-5 яшьлекләр) "Туганнан алып мәктәпкәчә"
инновацион мәктәпкәчә белем бирү программасына
(Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, Э.М. Дорофеева редакциясендә),
балалар бакчасчының төп белем бирү программасына таянып
укыту - эш программасы

Тәрбиячеләр: Габдрахманова Л.С. I кв.категорияле
Хадиева Ч.М. I кв.категорияле

2022 нче ел

**Эчтәлек**


| | |
|---|---|
| **Кереш** | |
| **I Максатчан бүлек** | |
| 1.1. Аңлатмалы язу | 3 |
| 1.1.2. Программаны тормышка ашыру максаты һәм бурычлары | 5 |
| 1.1.3. Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары | 5 |
| 1.1.4. 4-5 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре | 6 |
| 1.2.Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре | 7 |
| 1.2.1 Программаны үзләштерүнең көтелгән белем бирү нәтиҗәләре | 8 |
| 1.2.2.Мәктәпкәчә белем бирүне төгәлләү этабында максат ориентирлары | 12 |
| 1.2.3. Педагогик диагностика | 13 |
| **II. Эчтәлек бүлеге** | |
| 2.1. Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге | 14 |
| 2.1.1 Социаль-коммуникатив үсеш өлкәсе | 14 |
| 2.1.2 Танып белү үсеш өлкәсе | 17 |
| 2.1.3 Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе | 22 |
| 2.1.4 .Сәнгати-эстетик үсеш өлкәсе | 23 |
| 2.1.5. Физик үсеш өлкәсе | 28 |
| 2.1.6. Белем бирү өлкәләренең милли мәдәни төбәк чыганагына яраклаштырылган бурычлары (ЭРС) | 29 |
| 2.2. Программаны тормышка ашыруның ысуллары һәм юллары | 31 |
| 2.2.1. Гаилә белән үзара аралашу | 32 |
| **III.Оештыру бүлеге** | |
| 3.1. Уртанчылар төркемендә көндәлек режим | 38 |
| 3.2 Уртанчылар төркемендә белем бирү эшчәнлеге челтәре | 39 |
| 3.3. Сәламәтләндерү, чыныктыру планы | 40 |
| 3.4. Күңел ачу чаралары | 41 |
| 3.5. Материаль-техник методик кулланма | 42 |
| 3.6. Үстерешле предметлы тирәлекне оештыру үзенчәлекләре | 43 |
| Кушымта 1 Комплекслы тематик план (Проект) | 46 |
| Кушымта 2 Конструктив – модельле эшчәнлек | 105 |
| Кушымта 3 Кул эшеннән перспектив план | 110 |
| Кушымта 4 "Нәни эколог" түгәрәгенең тематик планы | 112 |
| 3.7. Кулланылган әдәбият | 128 |
| | |

## Кереш

Без тирән үзгәрешләр һәм икътисади үзгәртеп корулар чорында яшибез. Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия оешмаларының эше дә көннән-көн яңара, матур традицияләргә байый. Педагоглар яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле методларын эзлиләр, тәрбия эшендә халкыбызның күркәм традицияләренә, педагогик тәҗрибәсенә ныграк таяналар. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирелә."Об образовании в Российском Федерации" Федераль канунына нигезләнеп, Россиядә мәктәпкәчә белем бирү гомуми белем бирүнең беренче дәрәҗәдәге статусын алды. Белем бирү программаларын тормышка ашырганда мәктәпкәчә белем бирү ФДББС "Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации № 1155 от 17 октября 2013 года), нигезендә җайга салына. Аның төп бурычы- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру. Программаны төзегәндә белем бирү үсешендә хәзерге заман халыкара тенденцияләр исәпкә алынды:

- балада әйләнә-тирәгә яңа караш формалаштыру;
- практикада белем бирүнең төп юнәлешләрен (экологик, экономик, социаль) тормышкаашыру;
- эшчәнлектә балаларның шәхси тәҗрибәләрен (көнкүреш, культура, социаль, әхлакый) активкуллану;
- балалар инициативасын, белемнә омтылышын, мөстәкыйльлегенүстерү;
-белем бирү процессын нәтиҗәле итү өчен төрле эшчәнлекне берләштерү (интегральләштерү)
- балаларның уенга,куркынычсызлыкка, уңайлы әйләнә-тирәгә хокукын
саклау; -сыйфатлы белем алуга мөмкинлек тудыру;
- балаларны социумга актив кертү.

## I. Максатчан бүлек.

### 1.1. Аңлатмалы язу.

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт белем бирү стандарты”на нигезләнеп, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, Э.М.Дорофеева редакциясендәге ”Туганнан алып мәктәпкәчә” төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына, балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

Программаның төп *максаты* - мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру,шәхес культурасы-ның нигезле җирлеген формалаштыру,шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып,физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үс терү,баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә,мәктәптә укырга әзерләү,мәктәпкәчә яшьтәге баланың куркынычсыз яшәү рәвешен булдыру.

Бу максатлар бала эшчәнлегенең (уен, аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.

Бурычлар:

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен,аралашу,танып-белү,хезмәт,хәрәкәт,матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләрнең бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;
- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру; - балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү; - тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү); - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә учреждение тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау; - региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

Эш программасы үз эченә баланың һәрьяклап үсүен, аларның яшь һәм шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып төзелгән 5 төрле үсеш юнәлешен ала: социаль – коммуникатив үсеш, танып белү үсеше, сөйләм үстерү, сәнгати үсеш, физик үсеш.

Программаны тормышка ашыру срогы - 1 ел (2021-2022 уку елы)

Төркемнең эшчәнлеге төп гомум белем бирү Программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә:

- Федеральный Закон Российской Федерации «Об образовании в РФ» 29.12.2012№273
- Приказ Минобрнауки РФ от 17 октября 2013 г. № 1155. «Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования»
- Приказ Минобрнауки «Об утверждении Порядка разработки примерных основных образовательных программ, проведения их экспертизы и ведения реестра примерных основных образовательных программ» от 28 мая 2014года, №594
- Постановление Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15 мая 2013 г. N 26 г. Москва «Об утверждении СанПиН 1.2. 3685.21 от 28.01.2021г. «Санитарно эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации
режима работы дошкольных образовательных организаций»
- Федеральный Закон от 3 августа2018 №317-ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федерального закона «Об образовании в Российской Федерации»

### 1.1.2. Программаның тормышка ашыру максаты һәм бурычлары.

**Программаның максат:** баланың мәктәпкәчә балачагын тулы канлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәге тормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

**Бурычлары:**

-һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;

• төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия- белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;

• тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру;

• белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;

• балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;

• мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;

• балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү.

### 1.1.3. Программаны формалаштыру юнәлеше һәм принциплары

Программаны формалаштыруның юнәлеше һәм принциплары тулысынча Балтач муниципаль районы “Балтач №1 катнаш төрдәге балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең эш планына туры килә.

Программада белем бирүнең бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче һәм педагогны аның индивидуаль үзенчәлекләренә юнәлтүче үстерү функциясе беренче планга чыга, бу балачакның мәктәпкәчә чорының үзкыйммәтен тану турындагы хәзерге фәнни «Мәктәпкәчә тәрбия концепциясе»нә (авторлары В.В. Давыдов, В.А. Петровский һ.б.) туры килә.Программа балага карата гуманлылык һәм шәхес итеп карау мөнәсәбәтләрендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, шулай ук сәләтләрен һәм интегратив сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән.

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә кулланучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);
• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);
• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;
• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;
• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;
• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;
• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;
• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрлеләндерүгә юл куя;
• мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелә.

### 1.1.4. 4- 5 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгән рольдән үзләрен аера башлыйлар, уен процессында рольләр үзгәрергә мөмкин. Алар үзләре өчен түгел, ә уенны мәгънәле итү өчен уйный башлыйлар. Уендагы һәм чынбарлыктагы мөнәсәбәтләр аерымлана.
Сурәтләү эшчәнлеге шактый үсеш ала. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән форма ала. Кешенең график сурәте гәүдә, күз, авыз, борын, чәч, кайвакыт кием һәм аның детальләре булу белән характерлана. Сурәтләү эшчәнлегенең техник ягы камилләшә. Балалар төп геометрик фигураларны ясый, кайчы белән кисә, сурәтләрне кәгазьгә ябыштыра алалар һ.б.
Конструкцияләү катлаулана. 5- 6 детальдән торган корылмалар барлыкка килә. Уйлап чыгарылган конструкцияләү, шулай ук төзү эзлеклелеген планлаштыру күнекмәләре формалаша.
Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың уңай үзгәрешләре белән характерлана. Җитезлек, хәрәкәт координациясе үсә. Кечкенәләр белән чагыштырганда балалар бу яшьтә тигезлекне яхшы саклыйлар, зур булмаган тоткарлыкларны атлап чыгалар. Туп белән күнегүләр катлаулана.
Зиһенгә алу сәләте күбрәк үсеш ала. Балалар теге яки бу предметка охшаган форманы атый беләләр. Алар катлаулы объектларда гади формаларны аерып күрсәтә һәм гади формалардан катлаулы объектлар барлыкка китерә алалар. Балалар предмет төркемнәрен

сенсорик билгеләре – зурлыгы, төсе буенча тәртипкә салырга, биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле.
Хәтер күләме үсә. Балалар 7- 8 предметның исемен истә калдыра алалар. Истә калдыру мөмкинлекләре үсә. Алар олылар тапшырган эшне истә калдыралар, кечкенә шигырьләрне ятлый алалар һ.б.
Тасвирлы фикерләү сәләте үсә башлый. Балалар катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишүдә гади схемалаштырылган сурәтләр кулланалар. Алар схема буенча төзи, лабиринтлы мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күрә белү сәләте үсә. Объектларның пространствода урнашулары нигезендә, балалар аларның үзара йогынты ясашуы нәтиҗәсендә нәрсә килеп чыгасын әйтә алалар. Тик аларга читтән күзәтүче позициясенә басу һәм аларны күзаллап үзгәртү аларга авыр.
Күз алдына китерү, уйлап чыгару (воображение) сәләте үсә. Оригинальлекһәм ирекле булу кебек сыйфатлар формалаша. Балалар мөстәкыйль рәвештә бирелгән темага зур булмаган әкият уйлап чыгара алалар.
Игътибарлылык сәләте үсә. Бала 15- 20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли алырга сәләтле. Ул нинди дә булса эш эшләгәндә катлаулы булмаган шартны хәтерендә тотып тора ала.
Авазлар әйтелеше һәм дикция яхшыра. Сөйләм балаларның активлыкларын үстерә. Алар хайван тавышлары чыгаралар. Теге яки бу персонажның сөйләмен интонация белән аерып күрсәтә алалар. Сөйләмнең ритмик төзелеше, рифмасы игътибарга лаек. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш ала. Балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыгалар. Бер-берсе белән аралашканда балаларның сөйләме ситуациягә бәйле, ә олылар белән аралашканда ситуациягә бәйләнмәгән була.
Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Ул бала эләккән конкрет ситуациядән читкә тайпыла. Танып белү мотивы алга чыга. Аралашу процессында алган мәгълүматлар бик үк аңлашылып бетмәсәләр дә, балада кызыксыну уяталар.
Бала өлкәннәрнең үзен ихтирам итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зур әһәмияткә ия була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Шелтә, кисәтүләргә тискәре мөнәсәбәт туа. Артык үпкәләүчәнлек бу яшьнең феномены булып тора. Яшьтәшләре белән бала сайлап кына аралаша башлый. Ул кайбер иптәшләренә өстенлек бирә. Уен вакытында даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Ярышу үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен әһәмиятле. Бу үз чиратында *Мин* образының үсешенә, аны детальләштерүгә китерә.
Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү; рольле һәм тормышчан үзара бәйләнешләр барлыкка килү; сурәтләү эшчәнлеге үсү; үзең уйлап конструкцияләү; планлаштыру, зиһенгә алу сәләте камилләшү, образлы, хыялый фикерләү, танып белүдә мин-минлек ( минеке генә дөрес дигән позиция); хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү, *Мин* образының үсүе белән характерлана.

## 1.2. Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

### Максат ориентирлары

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы, аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя.

Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-норматив сыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналар өчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.
МББ ФДББСнда билгеләнгән максат ориентирлары Россия Федерациясенең бөтен мәгариф пространствосы өчен уртак булып тора.
Шулай итеп, «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы ориентирлары МББ ФДББСна һәм «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасына аңлатма язуында билгеләнгән максатларга һәм бурычларга нигезләнә, аларның Стандартлар белән туры килгән өлеше МББ ФДББС текстлары буенча бирелә. «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасында, Стандарттагы кебек үк, максат ориентирлары кече яшьтәге балалар өчен (мәктәпкәчә яшькә күчү этабында) һәм мәктәпкәчә яшьтәге зурлар төркемендәге балалар өчен (мәктәпкәчә белем бирүне төгәлләү этабында) тәгаенләнә.

### 1.2.1 Программаны үзләштерүнең көтелгән белем бирү нәтиҗәләре

**Шәхси белем бирү нәтиҗәләре:**

Ел ахырына балалар эшли белә:
- үзе турында гап-гади күзаллаулар (үз исемен, фамилиясен, яшен, җенесен , беренчел гендер күзаллаулары бар)
- үз-үзеңне уңай бәяләү, үз-үзеңә ышаныч, яхшы булу омтылышы;
- әхлак нормаларын үтәүгә (бозуга) шәхси мөнәсәбәт күрсәтү, гаделлеккә омтылу, әдәпсез гамәлләрдә хурлык хисе кичерү.
- Өлкәннәрнең, балаларның кичерешләренә эмоциональ караш күрсәтү.
- Иптәшләргә, өлкәннәргә ярдәм күрсәтүдә инициатива күрсәтү сәләте.
- Туган якка карата мәхәббәт һәм кызыксынуның беренчел нигезләре (Туган шәһәренең исемен белә).
- Туган илгә мәхәббәт һәм кызыксынуның беренче нигезләре (Туган илнең исемен белү, төп дәүләт бәйрәмнәре: Җиңү көне, Ватанны саклаучылар көне, 8 Март, Яңа ел, Россия армиясе, аның Ватанны саклауда роле турында гап-гади күзаллаулары булу).

**Универсаль белем бирү нәтиҗәләре**

Когнитив үсеш. Ел ахырына балалар эшли белә:
- Танып-белү , кызыксынучанлык (сәбәпләре, бәйләнешләре белән кызыксыналар, " ни өчен?» , "нигә? һ. б.).
- Эмоциональ-образлы предвосхищения элементлары (бала башлый радоваться һәм борчылу уңаеннан гына түгел, моннан тыш, ул ясый, хәзерге вакытта, әмма уңаеннан, моннан тыш, аңа әле эшләргә туры киләчәк).
-Тикшеренү эшчәнлеге, экспериментлар белән кызыксыну.
- Барлык хисләр органнарын актив кулланып, таныш һәм яңа ысулларны кулланып, предметларны мөстәкыйль рәвештә тикшерү (күрү, ишетү, тәм, сенсорик гамәлләре)
- Гади схематик сурәтләрдән файдалану, схема буенча төзү, лабиринт бурычларын хәл итү сәләте. Дәреслек пар. Ел ахырына балаларда түбәндәгеләр күренә: • яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәттә сайлау, ул бер - берсенә өстенлек бирүдә чагылыш таба.

**Белем бирү өлкәсендә белем бирү нәтиҗәләре: социаль-коммуникатив һәм уен эшчәнлеген үстерү.**

Ел ахырына балалар эшли белә:
- Яшьтәшләре белән уенда берләшеп, төрле рольләрне үз өстенә алырга.
-Рольле диалоглар алып барырга.
-Уен процессында рольләрне алыштырырга.
-Сюжетлы-рольле уеннарга атрибутлар сайлый белергә

-Инициативаны күрсәтергә һәм яңа рольләр яки гамәлләр тәкъдим итергә, сюжетны баетырга.
**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләре.** Ел ахырына балалар эшли белә:
-Үз-үзеңә гади хезмәт күнекмәләре күрсәтергә.
-Мөстәкыйль рәвештә киенергә, чишенергә, кием-салымны зурлар ярдәмендә төреп алып куерга.
-Мөстәкыйль ашарга, кашык, вилка, пычак, салфетка белән куллана белергә.
**Хезмәткә тарту.** Ел ахырына балалар эшли белә:
-Дәресләргә үз эш урынын әзерләргә, эш тәмамланганнан соң материалларны җыярга.
-Дежур вазифаларын башкарырга.
-Индивидуаль һәм коллектив йөкләмәләрне үтәргә, йөкләнгән бурычларга җаваплы карарга, аны яхшы башкарырга омтылырга.
**Куркынычсызлык нигезләрен формалаштыру**. Ел ахырына балалар эшли белә:
- Балалар бакчасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәргә.
-Урамда һәм транспортта үз-үзеңне тоту, элементар юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәргә,
(светофор сигналларының әһәмиятен аңларга; “Җәяүлеләр юлы” билгеләрен белергә һәм атарга; “Җәмәгать транспорты тукталышы”; машиналар йөрү өлешен, тротуарны аерырга,
җир асты җәяүлеләр кичүе, «зебра» җәяүлеләр кичүе һ. б.).
-Табигатьтә үз-үзеңне тотуның гади кагыйдәләрен (үсемлекләр һәм хайваннар белән куркынычсыз хезмәттәшлек итү, әйләнә-тирәлеккә сак караш ысуллары)үтәргә.
**Белем бирү өлкәсе “Танып-белү үсеше” Элементар математик күзаллаулар формалаштыру.** Ел ахырына балалар эшли белә:
-Предметларны төрле билгеләре буенча төркемнәргә берләштерергә (төсе, күләме һ.б.)
-5 кә кадәр санарга,“Барлыгы күпме?”соравына җавап бирергә.
-Предметларның күләмен санау нигезендә (5 эчендә),шулай ук ике төркем предметларын куеп карау юлы белән (парлар төзү) чагыштыру; нинди предметлар күбрәк,әзрәк,тигез күләмдә булуын билгеләргә.
-Ике предметны бер-берсенә, янәшә куеп карап зурлыгы буенча чагыштыру(зур-кечкенә,югарырак-түбәнәгрәк, озынрак-кыскарак,бертигез)
-Геометрик фигураларны аера һәм атарга(түгәрәк, квадрат, өчпочмак, шар,куб), аларның характерлы аерымлыкларын белергә.
Әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу, пространство мөнәсәбәтләренең мәгънәсен аңлау (өстә-аста, алда-артта, сулда — уңда, арада, янәшәдә, якында һ.б.)аста, алда-артта, сулда-уңда); сигналга тиешле юнәлештә хәрәкәт итү:алга һәм артка, өскә һәм аска (баскыч буенча).
-Тәүлекнең өлешләрен билгеләргә.
**“Конструктив-модельләү эшчәнлеге”.** Ел ахырына балалар эшли белә:
- Үз ниятең буенча конструкцияләргә.
- Төзелеш үрнәген анализлау.
- Үз төзелешеңне булдыру этапларын планлаштыру, конструктив карарлар табу.
-Рәсем, схема буенча төзелмәләрне булдыру.
- Коллектив белән эшләргә.

**Предметлы дөнья белән танышу**. Ел ахырына балалар эшли белә:
-Биналарда,мәйданчыкта, урамда очраган предметларны атарга; аларның билгеләнешен аңлатырга.
-Предметларны нинди материалдан эшләнгәнен белергә(кәгазь, металл, агач һ. б.).
-Төп гомумиләштерелгән сүзләрне кулланырга (мебель, кием-салым, аяк киеме һ. б.),
аларны классификацияләргә (һава, су,җир өсте транспорты һ. б.),аларны төрле үзенчәлекләре һәм билгеләре буенча аерырга һәм төркемләргә (барысы да агачтан,чәй сервизы,аш сервизы һ. б.).
-Җәмәгать транспорты турында күзалларга (“Ашыгыч ярдәм”,”Янгын сүндерү”,”Полиция”, МЧС машинасы).
**Табигать дөньясы белән танышу.** Ел ахырына балалар эшли белә:
-Һава торышын билгеләргә һәм атарга.
-Тере һәм тере булмаган табигатьтә сезонлы үзгәрешләрне күрергә һәм аерырга.
-Җирнең табигый күптөрлелеге турында күзалларга.
-Үсемлекләр дөньясы турында күзъаллау (агачлар,чәчәкләр, яшелчә, җиләк-җимеш); белергә һәм атарга кайбер үсемлекләр;кайбер үсемлекләрне танырга,аларның өлешләрен
атарга
-Кайбер ашарга яраклы һәм ашарга ярамаган гөмбәләрне белергә.
-Хайваннар дөньясы турында белергә(җәнлекләр, кошлар,балыклар,бөҗәкләр)
-Кайбер тарихи хайваннар турында күзъаллау(динозавлар).
-Йорт айваннарның күптөрлелеге турында күзъаллау йорт хайваннары,нәрсә ашыйлар, аларны ничек тәрбияләргә,алар кешегә нинди файда китерә.
**Социаль дөнья белән танышу.** Ел ахырына балалар белергә тиеш:
-Киң таралган һөнәрләр турында күзъаллый беләләр (тәрбияче,табиб,сатучы,шофер,пешекче һ.б),алар нәрсә эшлиләр,аларның эш кораллары нинди?
-Кайбер иҗади һөнәрләр турында күзаллауларга ия булу (рәссам, композитор,
язучы, шагыйрь, артист) һәм төп хәрби һөнәрләр (солдат, очучы, диңгезче һәм башкалар).
**“Сөйләм үсеше” белем өлкәсе буенча ел ахырына балалар белергә тиеш:**
-Сүзне аралашу өчен төп чара буларак куллану, шул ук вакытта сүз балаларның реаль мөнәсәбәтләрен алып баручы сүз рольле сөйләменнән аерылып тора.
-Уен һәм көнкүреш гамәлләрен сүз белән актив алып барырга.
-Антоним сүзләрне куллану.
-Сөйләмдә эмоцияне белдерүче (ачулы,күңелсез),эстетик сыйфатны (хәйләкәр,игелекле),эстетик характерлы (матур,күркәм) сүзләр кулланырга.
-Сүзнең беренче авазын билгеләргә.
-Картина буенча сөйли белергә.
**Матур әдәбиятка тарту.** Ел ахырына балалар белергә тиеш:
-Китап укырга, иллюстрацияле китаплар карарга кызыксыну уяту.

-Яраткан әкиятне, хикәяне атарга.
-Шигырьне, санамышларны яттан сөйли белергә.
-Зурлар ярдәмендә зур булмаган әкиятләрне сәхнәләштерә белергә (әкиятләрдән өзекләр), әкиятләрнең эчтәлеген сөйли белергә.
-Бирелгән темага мөстәкыйль әкият уйлап табарга.

**Белем өлкәсе . "Сәнгати-эстетик үсеш"**

Ел ахырына балалар белергә тиеш:

- рәсем сәнгате әсәрләренә эмоциональ яктан ярдәмчеллек, әйләнә-тирә предметларның (уенчыклар), табигать объектларының (үсемлекләр, хайваннар) матурлыгын күрсәтергә, шатлык хисе кичерергә; рәсем, лепка, аппликацияләрдә гади фәннәрне һәм күренешләрне сурәтләргә омтылырга, аларны образлы чагылдырырга.
- Иҗади һөнәрләргә кызыксыну күрсәтү (рәссам, язучы, композитор һ.б.)
- Различать төп жанрлары һәм сәнгать төрләре.
- Сәнгатьнең бер төре буларак архитектура турында беренчел күзаллаулар. 1 Яңа материал-ны үзләштерү Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү Уку эшчәнлеген оештыра белү. * Күргәзмәләргә, спектакльләргә һ. б. карарга кызыксыну күрсәтү. Сынлы сәнгать эшчәнлеге. Ел азагына балалар рәсем ясауда катнаша ала: • предметларны хисап формаларын булдыру, Төс сайлау юлы белән сурәтләргә.,

**Белем өлкәсе. "Физик үсеш".Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.**

Ел ахырына кадәр бала белергә тиеш::
-Гигиена күнекмәләрен үти (кулларны сабынлап юа,тарак белән куллана,кулъяулыгы белән файдалана, йөткергәндә авызын каплый).
-Ашау, юыну вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен саклый.
-Ризык кабул итүнең гап-гади кагыйдәләре (ашау приборлары,салфетка белән дөрес куллана,ашаганнан соң авызны чайкый).
- "Сәламәтлек" һәм "авыру"төшенчәләре турында күзаллый.
- Чыныгу, иртәнге зарядка, физик күнегүләрнең файдасы турында күзаллаулар.

**Физик культура.** Ел ахырына балалар белергә тиеш:
-Предметларны төрле ысуллар белән уң һәм сул кулы белән ыргыту.
-Тупны җирдә (идәндә) сикертү:5 тапкыр рәттән һәм аннан да күбрәк.
-Тупны 1.5 м.ераклыктан тотып тоту.
- Колоннага өчәр, дүртәр тезелә белү,колоннада һәм шеренгада тигезләнә белү, колоннада уңга, сулга, борылышлар эшли белү.
-Мөстәкыйль рәвештә бозлы юл буйлап шуу. (озынлыгы 5 м).
-Пространствода ориентлашу.
-Хәрәкәтчән һәм физик уеннарда катнашу.
- Шөгыльләрдән тыш (буш вакытта) физкультура җиһазларыннан файдалану.

### 1.2.2 Мәктәпкәчә белем бирүне төгәлләү этабында максат ориентирлары:

-Бала төп мәдәни чараларны, эшчәнлек ысулларын үзләштерә, эшчәнлекнең төрле төрләрендә — уенда, аралашуда, танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б да инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтә; үзенә шөгыль төрен, уртак эшчәнлек буенча катнашучыларны сайлап алырга сәләтле.
-Бала дөньяга, хезмәтнең төрле төрләренә, башка кешеләргә һәм үз-үзенә карата уңай мөнәсәбәткә ия, аңа үзенең урынын белү хас; яшьтәшләре һәм зурлар белән актив аралаша, уртак уеннарда катнаша.
-Килешүләргә, башкаларның ихтыяҗлары һәм хисләре белән исәпләшергә, аларның уңышсызлыкларын бүлешергә һәм уңышларына сөенергә сәләтле, үз хисләрен, шул исәптән үзенә ышаныч хисен дөрес белдерә, каршылыкларны чишәргә тырыша. Төрле мәсьәләләр буенча үз позициясен аңлатырга һәм якларга сәләтле.
-Уртак эшчәнлектә хезмәттәшлеккә һәм лидерлык, һәм башкару функцияләрен дә үтәргә сәләтле.
-Барлык кешеләрнең дә, социаль чыгышлары, нинди этник төркемгә керүләренә, дини һәм башка инануларына, физикһәм психик үзенчәлекләренә карамастан, тигез икәнен аңлый.
-Башка кешеләргә карата эмпатиягә ия, мохтаҗларга ярдәмгә килергә әзер тора.
-Башкаларны тыңлый белә һәм башкаларның да үзен аңлауларына омтыла.
-Баланың хыялга бирелүе үсешкә ирешкән, ул эшчәнлекнең төрле төрләрендә, һәм барыннан да элек уенда, гамәлгә ашырыла; уенның төрле формаларын һәм төрләрен уйный белә, шартлы һәм чынбарлыктагы хәлләрне аера ала; төрле кагыйдәләрне һәм социаль нормаларны үтәргә сәләтле. Килеп туган төрле хәлләрне тотып ала һәм аларны дөрес бәяли белә.
-Бала сөйләм теленә шактый оста, үзенең уйларын һәм теләкләрен белдерә, сөйләмне үзенең уйларын, хисләрен һәм теләкләрен аңлату өчен, аралашу вакытында сөйләм тезмәләре төзү, сүзләрдә авазларны аерып карау өчен куллана ала, балада грамоталылыкның алшартлары формалаша.
-Балада эре һәм вак моторика үскән; ул хәрәкәтчән, түзем, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен тикшерә һәм алар белән идарә итә ала.
-Бала ихтыяр көчен җыярга сәләтле, эшчәнлекнең төрле төрләре вакытында социаль тәртип нормаларын һәм кагыйдәләрен үти ала, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләрдә иминлекне саклау тәртибе кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена күнекмәләрен үти ала.
-Башланган эш өчен җаваплылык сизә.
-Кызыксынучанлык күрсәтә, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре белән кызыксына, табигать күренешләренә һәм кешеләр кылган гамәлләргә карата мөстәкыйль рәвештә аңлатмалар табарга тырыша; күзәтергә, экспериментлар ясарга һәвәс. Үзе турында, табигый һәм үзе яшәгән социаль дөнья турында башлангыч белемнәргә ия, балалар әдәбияты әсәрләре белән таныш, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. өлкәләр буенча элементар күзаллаулары бар; эшчәнлекнең төрле төрләре буенча, үзенең белем һәм күнекмәләренә таянып, карарлар кабул итүгә сәләтле.
-Яңалыкны кабул итәргә әзер, ягъни белем алуга, алга таба мәктәптә, институтта укуга карата уңай мотивациягә омтылыш күрсәтә.
-Тормышка (аның төрле формаларында) хөрмәт белән карый һәм әйләнә-тирә мохит турында кайгырта.

-Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына, халык сәнгате һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә (музыкага, биюгә, театраль эшчәнлеккә, рәссамлык эшчәнлегенә һ.б.) эмоциональ бәя бирә.
-Патриотик хисләр кичерә, үз иле, аның казанышлары белән горурлана, аның географик төрлелеге, күпмилләтлелеге, иң мөһим тарихи вакыйгалары хакында күзаллаулары бар.
-Үзе, гаилә, традицион гендер юнәлешләрен дә эченә алган традицион гаилә кыйммәтләре хакында беренчел күзаллауларга ия, үз җенесенә һәм капма-каршы җенескә карата ихтирамлы.
-Гомуми кабул ителгән элементар нормаларны үти, «нәрсә яхшы, нәрсә начар» булуы турында беренчел күзаллауларга ия, яхшы гамәлләр кылырга омтыла; өлкәннәрне хөрмәт итә һәм кечкенәләр турында кайгырта.
-Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллауларга ия. Сәламәт яшәү рәвешен кыйммәт буларак кабул итә.

### 1.2.3.Педагогик диагностика

«Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыру балаларның индивидуаль үсешен бәяләүне күздә тота. Мондый бәяләү педагогик хезмәткәр тарафыннан педагогик диагностика (мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешенә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү белән бәйле һәм аларны алга таба планлаштыруның нигезендә ятучы бәя бирү) кысаларында уздырыла.
Педагогик диагностика балаларның гадәти һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыгын күзәтү барышында үткәрелә. Педагогик диагностика өчен инструментарий — балалар үсешен күзәтү карталары, алар һәрбер баланың индивидуаль динамикасын һәм үсеш перспективаларын түбәндәгеләр барышында билгеләргә мөмкинлек бирә:• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);
• уен эшчәнлеге;
• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара);
• проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);
• сәнгати эшчәнлек;
• физик эшчәнлек.
Педагогик диагностика нәтиҗәләре фәкать түбәндәге белем бирү бурычларын хәл итү өчен кулланыла ала:
1) белем бирүне индивидуальләштерү (шул исәптән балага булышлык күрсәтү, аның белем бирү траекториясен булдыру яисә аның үсеш үзенчәлекләренә профессиональ төзәтмә кертү);
2) балалар төркеме белән эшне оптимальләштерү.
Белем бирү эшчәнлеге барышында балаларның индивидуаль динамикасын бәяләү һәм үз гамәлләренә төзәтмә кертү өчен педагоглар диагностик ситуацияләр булдырырга тиеш.

## II.Эчтәлек бүлеге.
## 2.1. Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге.

2–7 яшьлек балалар белән психологик-педагогик эш эчтәлеге «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати-эстетик үсеш», «Физик үсеш» белем бирү өлкәләре буенча бирелә. Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча психологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итүбелән беррәттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә. Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала

### 2.1.1. “Социаль-коммуникатив үсеш” белем бирү өлкәсе.

«Социаль-коммуникатив үсеш, әхлакый һәм рухи кыйммәтләрне кертеп, җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны һәм кыйммәтләрне үзләштерүгә; баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм үзара бәйләнешен үстерүгә; мөстәкыйльлеген, максатчанлыгын һәм үз гамәлләрен үзе җайга салуын булдыруга; социаль һәм эмоциональ интеллектны, киң күңеллелекне, хәлгә керә белүне үстерүгә, яшьтәшләре белән уртак эшчәнлеккә әзерлек формалаштыруга, Оешмадагы балалар һәм өлкәннәр бергәлеге һәм үз гаиләләренеке булу хисен һәм аларга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә; хезмәтнең һәм иҗатның төрле төрләренә уңай караш формалаштыруга;
көнкүрештә, социумда, табигатьтә үз-үзеңне имин тоту нигезләрен булдыруга юнәлтелгән»[1].

**Бурычлар:**

**1. Социальләштерү, аралаша белү сыйфатларын үстерү, әхлак тәрбиясе.**
**2. Бала гаиләдә һәм берләшмәдә**
**3. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек, хезмәт тәрбиясе.**
**4. Куркынычсызлык нигезләрен формалаштыру.**

### 4-5 яшьлек балалрның социальләштерү, аралаша белү сыйфатларын үстерү, әхлак тәрбиясе.

Баланың әхлак нормаларын үтәүгә: үзара ярдәмләшүгә, кыерсытылган кешенең хәленә керүгә һәм кыерсытучының гамәлләре белән ризалаш- мауга карата шәхси мөнәсәбәте; гадел булган, яшьтәшенең үтенеченә юл куйган (шакмакларны тигез бүлгән) кешенең гамәлләрен хуплау формалашу- га булышлык итү.

Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләр формалаштыру буенча эшне дәвам итү; балаларның игътибарын бер-берсенең яхшы гамәлләренә юнәлтү.

Коллектив уеннарга, үзара яхшы мөнәсәбәтләр кагыйдәләренә өйрәтү. Тыйнаклык, ярдәмчеллек, гадел, көчле һәм кыю буллу теләге тәрбияләү;ямьсез гамәл өчен оят хисе кичерергә өйрәтү.

Сәламләү, саубуллашу, мәктәпкәчә учреждение хезмәткәрләрен исемнәре һәм әтиләренең исемнәре белән атау, өлкәннәр сөйләшүенә ка- тышмау, үз үтенечеңне әдәпле итеп җиткерү, күрсәтелгән хезмәт өчен рәх- мәт белдерү зарурлыгы турында балаларның исләренә төшереп тору.

**4-5 яшьлек бала гаиләдә һәм берләшмәдә**.

**«Мин» образы.** Баланың үсүе һәм үсеше, аның үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында күзаллаулар («мин кечкенә идем, мин үсәм, мин зур була- чакмын») формалаштыру. Балаларда аларның хокуклары (уйнарга, дустанә мөнәсәбәткә, яңа белемнәргә һ.б.) һәм балалар бакчасындагы төркемдәге, өйдәге, урамдагы бурычлары (мөстәкыйль ашау, киенү, уенчыкларны җыеп кую һ.б.) турындагы беренчел күзаллауларны формалаштыру. Һәр балада аның яхшы булуы, аны яратулары турында инанганлык формалаштыру. Беренче гендер күзаллауларын формалаштыру (малайлар көчле, кыю; кызлар мөлаем, нәфис).

**Гаилә.** Балаларның гаилә, аның әгъзалары турындагы күзаллауларын тирәнәйтү. Туганлык мөнәсәбәтләре турында беренчел күзаллаулар булдыру (улы, әнисе, әтисе, кызы һ.б.).

Баланың өйдәге тормышта нинди бурычлары (уенчыкларны җыеп кую, табын әзерләүдә булышу һ.б.) булуы турында кызыксыну. **Балалар бакчасы.** Балаларны балалар бакчасы һәм аның хезмәткәрләре белән таныштыруны дәвам итү. Балалар бакчасы бүлмәләрендә ориентлаша белү сәләтен камилләштерү. Балаларда әйберләргә карата сакчыл мөнәсәбәтне ныгыту, әйберләрне тиешенчә файдаланырга, аларны урыннарына куярга өйрәтү.

Балалар бакчасы традицияләре белән таныштыру. Баланың үзе турында коллектив әгъзасы сыйфатында күзаллауларын ныгыту, башка балалар белән бергәлек хисен үстерү. Балалар бакчасында төркемне һәм залны, участокны бизәүдәге үзгәрешләрне (затлы, матур уенчыкларның, балалар рәсемнәренең күркәмлеге һ.б.) күрә белү сәләтен формалаштыру. Фикер алышуга һәм мөмкин кадәр төркемне бизәүдә катнашуга, төркемнең символикасын һәм традицияләрен булдыруга җәлеп итү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек,хезмәт тәрбиясе**

**Культура-гигиена күнекмәләре.** Балаларда пөхтәлек, үзләренең тышкы кыяфәтләрен кайгырту гадәте тәрбияләүне дәвам итү.Мөстәкыйль рәвештә юыну, пычрануга карап, ашау алдыннан, бәдрәфтән чыккач кулларны сабынлап юу гадәте тәрбияләү.Тарак, кулъяулыктан файдалану, йөткергәндә һәм төчкергәндә читкә борылу, авызны һәм борынны кулъяулык белән каплау гадәтен ныгыту.

[1] МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара

Пөхтә ашау: ризыкны азлап алу, яхшылап чәйнәү, тавыш-тын чыгармыйча ашау, өстәл приборларыннан (кашык, чәнечке), салфеткадан дөрес файдалану, ашаганнан соң авызны чайкау күнекмәләрен камилләштерү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Үзлектән киенү, чишенә белү күнекмәләрен камилләштерү. Өс киемен җыйнак итеп төрергә һәм эләргә, өлкән кеше ярдәмендә аны тәртипкә китерергә (чистарту, киптерү) өйрәтү. Җыйнак һәм пөхтә булу теләге тәрбияләү.

Үз эш урынын мөстәкыйль рәвештә әзерләргә, рәсем, әвәләү, аппликация дәресләре тәгәлләнгәч аны җыештырырга (кечкенә банкаларны, пумалаларны юу, өстәлне сөртү һ.б.) өйрәтү.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт теләге тәрбияләү. Кушылган биремгә карата җаваплылык мөнәсәбә- те (эшне ахыргача җиткерә белү һәм җиткерү теләге, аны яхшы башкару омтылышы) формалаштыру. Индивидуаль һәм коллектив йөкләмәләрне башкару, үз хезмәтенең башкалар өчен әһәмиятен аңлау

тәрбияләү; тәрбияче ярдәмендә коллектив эшне бүлешү турында килешенү, уртак биремне вакытында башкарып чыгу турында кайгырту формалаштыру. Иптәшләренә, өлкән кешеләргә ярдәм итү инициативасын хуплау.
Балаларны мөстәкыйль рәвештә балалар бакчасының төркем бүлмәсендә һәм участогында тәртип сакларга өйрәтү: төзелеш материалын, уенчыкларны урыннарына җыеп кую; тәрбиячегә китапларны, тартмаларны ябыштырырга булышу. Балаларны ашханәдә мөстәкыйль рәвештә дежурлык вазифаларын башкарырга өйрәтү: җыйнак итеп ипи савытларын, тәлинкәләре белән чынаякларны, тирән тәлинкәләрне урнаштыру, салфетка савытларын, өстәл приборларын (кашыклар, чәнечкеләр, пычаклар) кую.
**Табигатьтәге хезмәт.** Балаларның үсемлекләрне һәм хайваннарны карау- тәрбияләү теләген хуплау; үсемлекләргә су сибү, балыкларны ашату, суэчергечләрне юу, аларга су салу, улакка азык салу (тәрбияче катнашында).
Балаларны язгы, җәйге һәм көзге чорларда булдыра алганча яшелчә бакчасында һәм чәчәклектә эшләүгә (орлыклар чәчү, су сибү, уңышны җыю), кышкы чорда кар көрәүгә җәлеп итү.
Балаларны кошларга кышкы чорда ашату өчен үлән үстерүгә; кышлаучы кошларны ашатуга җәлеп итү.
Тәрбиячегә хезмәт эшчәнлегендә кулланылучы җиһазларны тәртипкә китерүдә (чистарту, киптерү, тиешле урынга илтү) булышу омтылышын формалаштыру.
**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Балаларны, игътибарларын якын кешеләре хезмәтенең әһәмиятенә юнәлтеп, аларның һөнәрләре белән таныштыру. Әти-әниләренең һөнәрләренә карата кызыксыну формалаштыру.

## Куркынычсызлык нигезләрен формалаштыру

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының күптөрлелеге, терек булмаган табигать күренешләре белән таныштыруны дәвам итү.Хайваннар һәм үсемлекләр белән үзара тәэсир итешү ысуллары, таби-гатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында элементар күзаллаулар формалаштыру.«Ашарга яраклы», «ашарга яраксыз», «дару үләннәре» төшенчәләрен аңлауны формалаштыру.Куркыныч бөҗәкләр һәм агулы үсемлекләр белән таныштыру.

**Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.** Күзәтүчәнлек, балалар бакчасында бина эчендә һәм участокта, якын-тирәдә ориентлаша белү сәләтен үстерү.
«Урам», «юл», «урам чаты», «юл чаты», «җәмәгать транспорты тукталышы» төшенчәләре һәм урамда үз-үзеңне тотуның элементар кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү. Балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәүнең зарур булуын аңлауга китерү. Балаларның светофорның кирәклеге һәм полицейскийның эше турындагы белемнәрен ачыклау.Балаларны шәһәр транспортының төрләре, аларның тышкы күренешләренең һәм кулланылышының үзенчәлекләре белән таныштыру («Ашыгыч ярдәм», янгын сүндерү машинасы, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (МЧС) машинасы, «Полиция», трамвай, троллейбус, автобус).
Юл хәрәкәте билгеләре: «Җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу урыны»,«Җәмәгать транспорты тукталышы» белән таныштыру.
Җәмәгать транспортында үз-үзеңне культуралы тоту күнекмәләре формалаштыру.
**Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы.** Уеннар вакытында үз-үзеңне хәвефсез тоту кагыйдәләре белән таныштыру.
Тормышка һәм сәламәтлеккә куркыныч тудыручы хәлләр турында сөйләү.
Көнкүреш приборларының (тузан суырткыч, электр чәйнеге, үтүк һ.б.) кирәклеге, эше һәм алардан файдалану кагыйдәләре белән таныштыру.Өстәл приборларыннан (чәнечке, пычак), кайчыдан файдалану күнекмәләрен ныгыту.
Велосипедта йөрү кагыйдәләре белән таныштыру.
Таныш булмаган кешеләр янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.
Балаларга янгын сүндерүчеләр эше, янгыннарның килеп чыгу сәбәпләре һәм янгын вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү.

### 2.1.2. «Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсе

«Танып белү үсеше баланың мәнфәгатьләре, кызыксынучанлыгы һәмтанып белү мтылышы үсешен; танып белү гамәлләре, аңы формалашуын;хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен; үзе, башка кешеләр, әйләнә-тирәдәге объектлар, әйләнә-тирәдәге объектларның үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, микъдар,сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт, хәрәкәт һәм тыныч халәт,сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.), туган җир һәм Туган ил турындагы беренчелкүзаллаулары, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, Ватаныбызның традицияләре һәм бәйрәмнәре, кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, аның табигатенең үзенчәлекләре, дөньядагы илләрнеңһәм халыкларның күптөрлелеге турындагы күзаллаулары формалашуын күздә тота»[1].

**Максат:** Элементар математик күзаллаулар формалаштыру. Элементар математик күзаллаулар, әйләнә-тирә объектларының төп сыйфатлары һәм бәйләнешләре турындагы беренчел күзаллаулар формалаштыру.

**Микъдар һәм исәп.** Балаларга күплекнең («күп») төрле сыйфатлы элементлардан: төрле төстәге, зурлыктагы, формадагы предметлардан тору ихтималы турында күзаллау мөмкинлеге бирү; предметларны парлап урнаштыру нигезендә (санамыйча гына) күплекләрнең тигезлеген яки тигез булмавын ачыклау нәтиҗәсендә аларның өлешләрен чагыштырырга өйрәтү. Балаларның сөйләменә «Биредә түгәрәкләр күп, аларның бер өлеше — кызыл, икен- челәре зәңгәр төстә; кызыл түгәрәкләр зәңгәрләренә караганда күбрәк, зәңгәр түгәрәкләр кызылларына караганда азрак» яки «кызыл һәм зәңгәр түгәрәкләр саны бертигез» гыйбарәләрен кертү.
Исәпләү кагыйдәләрен кулланып, 5 кә кадәр санарга өйрәтү (күрсәтеп башкару нигезендә): саннарны тәртип буенча атау; һәр санны санала торган төркемдәге бер предмет белән бәйләү; соңгы санны саналган барлык предметларга карата куллану, мәсәлән: «Бер, ике, өч — барлыгы өч түгәрәк». Предметларның 1–2, 2–2, 2–3, 3–3, 3–4, 4–4, 4–5, 5–5 саннары белән аталган ике төркемен чагыштыру.Тәртип буенча санау турында булмавы турында күзаллау формалаштыру.Микъдар һәм тәртип саннарын дөрес кулланырга, «Ничә?», «Исәп буенча ничәнче?», «Ничәнче урында?»сорауларына җавап бирергә өйрәтү.

Кечерәк төркемгә бер (җитмәгән) предмет өстәп яки зуррак төркемнән бер (артык) предметны алып, ике ысул белән тигез булмаган төркемнәрне тигезләргә өйрәтү («2 куянга 1 куян өстәдек, 3 куян булды һәм чыршылар да өчәү. Чыршылар һәм куяннар саны бертигез — 3 һәм 3» яки: «Чыршылар күбрәк (3), ә куяннар азрак (2). 1 чыршыны алып куйдык, хәзер чыршылар да 2 булды. Чыршылар һәм куяннар саны тигезләште: 2 һәм 2».
Күпсанлы төркемнән предметларны санап чыгу; үрнәкләре яки кушылган (бирелгән) сан буенча 5 саны чикләрендә билгеле бер санда предметларны кую, китерү (4 этәч санап ал, 3 куян алып кил).
Төркемдәге предметлар бер-берсеннән төрле ераклыкта урнашканда, алар зурлыклары, урнашу рәвеше буенча бер-берсеннән аерылып торган халәттә санау-исәпләү нигезендә предмет төркемнәренең тигезлеген (тигез булмавын) билгеләү.
**Зурлык.** Ике предметны зурлыклары (озынлык, киңлек, биеклек) буенча чагыштыра белүне камилләштерү, шулай ук ике предметны бер-берсе өстенә яки янына кую юлы белән аларны калынлыклары буенча чагыштырырга өй- рәтү; сыйфатлар кулланып, чагыштыру нәтиҗәләрен сөйләмдә чагылдыру (озынрак — кыскарак, киңрәк — таррак, биегрәк — тәбәнәгрәк, калынрак — юкарак яки озынлык, киңлек, биеклек, калынлык буенча тигез (бертөрле)).
Предметларны зурлыкның ике билгесе буенча чагыштырырга өйрәтү (кы зыл тасма яшеленнән озынрак һәм киңрәк, сары шарф зәңгәреннән кыскарак һәм таррак).
Төрле озынлыктагы (киңлектәге, биеклектәге), калынлыктагы 3–5 предмет арасындагы зурлык чагыштырмаларын билгеләү, бу предметларны билгеле бер эзлеклелектә — зурлык кими яки үсә бару тәртибендә урнаштыру. Балаларның актив сөйләменә предметларның зурлык чагыштырмаларын белдерүче төшенчәләр кертү («бу (кызыл) манара — арада иң биеге, бу (кызгылт-сары) манара тәбәнәгрәк, бу (алсу) манара тагын да тәбәнәгрәк, ә бу (сары) манара — арада иң тәбәнәге» һ.б).
**Форма.** Балаларның геометрик фигуралар — түгәрәк, квадрат, өчпочмак, шулай ук шар, куб турындагы күзаллавын үстерү. Күрү һәм тою-хәрәкәт анализаторлары ярдәмендә фигураларның үзенчәлекле билгеләрен (почмаклар булу һәм булмау, тотрыклылык, хәрәкәтчәнлек һ.б.) аерырга өйрәтү. Түгәрәк, квадрат, өчпочмак белән чагыштырып, балаларны турыпочмаклык белән

таныштыру. Балаларны турыпочмаклыкны, аның элементларын — почмакларын һәм якларын аерырга һәм атарга өйрәтү. Фигураларның төрле зурлыкта була алулары турында күзаллау формалаштыру: зур — кечкенә куб (шар, түгәрәк, квадрат, өчпочмак, турыпочмаклык).

Предметларның формасын билгеле геометрик фигуралар белән тиңләштерергә өйрәтү: тәлинкә — түгәрәк, яулык — квадрат, туп — шар, тәрәзә, ишек — турыпочмаклык һ.б.

**Тирәлектә ориентлашу.** Үзеннән читкә таба тирәлек юнәлешләрен билгеләү, билгеләнгән юнәлештә (алга — артка, уңга — сулга, югарыга — түбәнгә) хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, предметларның үзеңә карата урнашуын сүзләр белән билгеләү (каршымда — өстәл, уң ягымда — өстәл, сул ягымда — тәрәзә, артымдагы киштәләрдә — уенчыклар).

Тирәлек чагыштырмалары белән таныштыру: ерак — якын (йорт якында урнашкан, ә каен еракта үсә).

**Вакыт буенча ориентлашу.** Балаларның тәүлек өлешләре, аларның характерлы үзенчәлекләре, эзлеклелеге (иртә — көндез — кич — төн) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

«Кичә», «бүген», «иртәгә» сүзләренең мәгънәләрен аңлату.

### Танып белү-тикшеренү эшчәнлеген үстерү

**Танып белү-тикшеренү эшчәнлеге.** Балаларны махсус эшләнгән сизем- ләү эталоннары системасы ярдәмендә төрле объектларны тикшерүнең го- мумиләштерелгән ысуллары белән таныштыруны дәвам итү, аңга кабул итү гамәлләрен үзләштерүгә булышу. Яңа объектны гамәли тикшерү процессында аның турында мәгълүматлар ала белү сәләте формалаштыру.

Эшчәнлекнең бурычына һәм тәкъдим ителүче алгоритмына тәңгәл эзлекле гамәлләр башкаруны формалаштыру. Танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә өлкән кеше тарафыннан тәкъдим ителгән модельләрне аңларга һәм файдаланырга өйрәтү.

**Сиземләүне үстерү.** Эшчәнлекнең төрле төрләрендә сиземләүне үстерү эшен дәвам итү. Балаларны предметларның һәм объектларның киң даирәсе, аларны тикшерүнең яңа ысуллары белән таныштырып, сиземләү тәҗрибәсен баету. Предметларны һәм объектларны тикшерүнең элегрәк булдырылган күнекмәләрен ныгыту.

Барлык сиземләү органнарын (тоемлау, күрү, ишетү, тәм тою,ис сизү) актив файдалану юлы белән балаларның аңга кабул итүен камилләштерү. Сиземләү тәҗрибәсен һәм алынган тәэсирләрне сөйләмдә ныгытуны баету.

Геометрик фигуралар (түгәрәк, өчпочмак, квадрат, турыпочмаклык, овал), төсләр (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, кызгылт-сары, шәмәхә, ак, соры) белән таныштыруны дәвам итү.

Тоюны үстерү. Капшау, кагылу, сыпыру нәтиҗәсендә төрле материаллар белән таныштыру, тоюларны сыйфатлап (шома, салкын, йомшак йонлы, каты, чәнечкеле һ.б.) башкарыла.

Эшчәнлекнең төрле төрләре процессында образлы рәвештә аңга кабул итү нигезендә образлы күзаллаулар формалаштыру. Предметлар сыйфатының гомум кабул ителгән үзлекләре (төс, форма, зурлык, авырлык һ.б.) буларак эталоннардан файдалануны үстерү; предметлар- ны 1–2 сыйфатлары (төс, зурлык, материал һ.б.) буенча сайлап алу.

**Проектлау эшчәнлеге.** Проектлау-тикшеренү эшчәнлегендә беренчел күнекмәләрне үстерү, бу эшчәнлекнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерүдә һәм аларны яшьтәшләргә тәкъдир итү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтү. Ата-аналарны балаларның тикшеренү эшчәнлегендә катнашуга җәлеп итү.

**Дидактик уеннар.** Предметларның тышкы билгеләрен чагыштыру, аларны төркемләштерү күнекмәләрен камилләштереп, балаларны предметларның үзлекләре турындагы күзаллауларны ныгыту
Балаларның тою, ишетү, тәм тою сиземләүләрен камилләштерү («Капшап (тәм буенча, яңгыраш буенча) ачыкла»). Күзәтүчәнлекне һәм игътибарны үстерү («Нәрсә үзгәрде?», «Йөзек кемдә?»).
Балаларга иң гади өстәл уеннары («Домино», «Лото») кагыйдәләрен үзләштерергә булышу га юнәлтелгән уеннарга өйрәтү; өлешләрдән бербөтен төзү (шакмаклар, мозаика, пазллар).

## Предметлы тирәлек белән таныштыру

Балаларның әйләнә-тирә дөнья объектлары турындагы күзаллауларын киңәйтү өчен шартлар тудыру. Балаларга эшчәнлекнең төрле төрләрендә (уенда, хезмәттә, рәсем ясаганда, аппликация эшләгәндә һ.б.) кирәк булган предметлар турында сөйләү. Балаларның җәмәгать транспорты (автобус, поезд, самолет, теплоход) турындагы белемнәрен киңәйтү.
Балаларны предметларның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, аларда предметларның төсен, формасын, зурлыгын, авырлыгын ачыклау теләге уяту. Предметларның нинди материаллардан (пыяла, металл, резина, күн, пластмасса) эшләнүе, аларның үзлекләре һәм сыйфатлары турында сөйләү. Предметны билгеле бер материалдан (машиналар корпусын — металлдан, шинны — резинадан һ.б.) эшләүнең максатка ярашлы булуын аңлату.
Уенчык һәм көнкүреш кирәк-яраклары тарихы мисалында кеше хезмәте төрләренең һәм көнкүрешнең үзгәрүе турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

## Социаль дөнья белән таныштыру

Җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү.
Балаларны җәмәгать транспорты (автобус, поезд, самолет, теплоход) турындагы белемнәрен киңәйтү.
Мәктәп турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.
Мәдәни күренешләр (театр, цирк, зоопарк, вернисаж), аларның атрибутлары, аларда эшләүче кешеләр, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.
Шәһәрдәге һәм авыл җирендәге тормыш һәм хезмәт үзенчәлекләре турында элементар күзаллаулар булдыру (балаларның үз тәҗрибәсенә таянып). Төрле һөнәрләр (шофер, почта таратучы, сатучы, табиб һ.б.) белән таныштыруны дәвам итү; хезмәт гамәлләре, хезмәт кораллары, хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларны киңәйтү һәм баету.
Балаларны акча, аннан файдалану мөмкинлекләре белән таныштыру. Туган якка мәхәббәт хисе тәрбияләүне дәвам итү; балаларга туган шәһәрләренең (поселокның) иң матур, истәлекле урыннары турында сөйләү.
Балаларда дәүләт бәйрәмнәре турында аларга аңлаешлы күзаллаулар булдыру.
Россия армиясе, Ватаныбызны саклаучы сугышчылар (чик сакчылары, диңгезчеләр, очучылар) турында сөйләү.

## Табигать дөньясы белән таныштыру

Балаларның табигать турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Йорт хайваннары, декоратив балыклар (вуалькойрык һәм телескоптан тыш, алтын балыклар, кәрәкә һ.б.), кошлар (попугайлар, кенәриләр һ.б.) белән таныштыру.

Балаларны сөйрәлүчеләр классы вәкилләре (кәлтә, ташбака), аларның тышкы кыяфәтләре һәм хәрәкәтләнү ысуллары (кәлтә озынча буйлы, аның озын койрыгы бар, ул койрыгын өзеп калдырырга мөмкин; кәлтә бик тиз йөгерә) белән таныштыру.

Балаларның кайбер бөҗәкләр (кырмыска, күбәләк, коңгыз, камка) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Җимешләр (алма, груша, слива, персик һ.б.), яшелчәләр (помидор, кыяр, кишер, чөгендер, суган һ.б.) һәм җиләкләр (кура җиләге, карлыган, крыжов- ник һ.б.), гөмбәләр (майлы гөмбәләр, баллы гөмбәләр, ал гөмбәләр һ.б.) ту- рындагы күзаллауларны киңәйтү. Балаларның үләннәр һәм бүлмә гөлләре (кына гөле, фикус, хлорофитум, яран, бегония, примула һ.б.) турындагы белемнәрен ныгыту; аларны карау ысуллары белән таныштыру.

Агачларның 3–4 төрен (чыршы, нарат, каен, усак һ.б.) танырга һәм атап әйтергә өйрәтү.

Тәҗрибә эшчәнлеге процессында балаларның ком, балчык һәм ташның үзлекләре турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Участокка очып килүче кошларны (ала карга, күгәрчен, песнәк, чыпчык, кызылтүш һ.б.) күзәтүне оештыру, кышын аларны ашату.

Балаларның кешеләр, хайваннар, үсемлекләр яшәеше өчен иң кирәкле шартлар (һава, су, туклану һ.б.) турындагы күзаллауларын ныгыту.

Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә өйрәтү. Үсемлекләрне һәм хайваннарны саклау турында сөйләү.

Сезонлы күзәтүләр

**Көз.** Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә һәм атап әйтеп би- рергә өйрәтү: салкынайтты, явым-төшемнәр, җил, яфраклар коелу, җимешләр һәм тамыразыклар өлгерә, кошлар көньякка очып китәләр.

Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасындагы иң гади бәйләнешләрне ачыклау (салкынайтты — күбәләкләр, коңгызлар юкка чыкты; чәчәкләр сулды һ.б.).Үсемлек орлыкларын җыюда катнашуга җәлеп итү.

**Кыш.** Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, көзге һәм кышкы пейзажларны чагыштыру.

Кошларның урамда һәм табигать почмагында үз-үзләрен тотышын күзәтү.

Кошларның кардагы эзләрен карау һәм чагыштыру. Кышлаучы кошларга ярдәм итү, аларны атап әйтү.

Балаларның салкында суның бозга, боз сөңгеләренә әверелүе, бозның һәм карның җылы бүлмәдә эрүе турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Кышкы күңел ачуларда катнашуга җәлеп итү: таудан чанада шуу, чаңгыда йөрү, кардан әйберләр әвәләп ясау.

**Яз.** Балаларны ел фасылын танырга һәм атап әйтергә өйрәтү; яз билгеләрен аерып күрсәтү: кояш җылырак яктырта башлады, агачларда бөреләр бүртте, үлән пәйда булды, умырзаялар чәчәк атты, бөҗәкләр пәйда булды.Балаларга яз көне күп кенә бүлмә гөлләренең чәчәк атуы турында сөйләү. Балаларны яшелчә бакчасындагы һәм чәчәклектәге эшләргә җәлеп итү.

**Җәй.** Балаларның табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү: чиста зәңгәр күк йөзе, кояш якты яктырта, эсселек, кешеләр җиңелчә киенгән, кызыналар, су коеналар.
Эшчәнлекнең төрле төрләре процессында балаларның ком, су, ташлар һәм балчыкның үзлекләре турындагы күзаллауларын киңәйтү.
Җәй көне күп кенә җимешләрнең, гөмбәләрнең өлгерүе; хайваннарның балалары үсә төшү турындагы белемнәрне ныгыту.

### 2.1.3 «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе

«Сөйләм үсеше аралашу һәм мәдәният чарасы буларак сөйләмгә ия булуны; актив сүзлекне баетуны; бәйләнешле, грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик сөйләмне; сөйләм иҗаты үсешен; сөйләмнең аваз һәм интонация культурасы, фонематик ишетү сәләте үсешен; китап культурасы, балалар әдәбияты белән танышуны, балалар әдәбиятының төрле жанрла- ры текстларын ишетеп аңлауны; укырга-язарга өйрәтүнең алшарты буларак авазлы аналитик-синтетик активлык формалашуны үз эченә ала»[1].

**Төп максатлар һәм бурычлар**

**Сөйләм үстерү.** Өлкәннәр һәм балалар белән ирекле аралашуны үстерү, тирә-юньдәгеләр белән үзара тәэсир итешүнең конструктив ысулларына һәм чараларына ия булу.
Балаларда сөйләм теленең барлык компонентларын: сөйләмнең грамматик төзелешен, бәйләнешле сөйләмне — аның диалогик һәм монологик формаларын үстерү; сүзлек запасы формалаштыру, сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләү.
Тәрбияләнүчеләрнең гамәли рәвештә сөйләм нормаларына ия булуы.
**Матур әдәбият**. Укуга карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү; әдәби сөйләмне үстерү.
Матур әдәбият әсәрләрен тыңлау теләге һәм тыңлый белү, вакыйгалар барышын күзәтә белү сәләте тәрбияләү.
**Үсешкә булышлык итүче сөйләм мохите.** Балалар белән бергә алар өчен гадәти тирәлек чикләреннән читтәге предметлар, күренешләр, вакыйгалар турындагы сөйләшү.
Балалар сөйләгәнне тыңлау, аларның җавапларына төгәллек кертү, предмет, күренеш, торыш, гамәл үзенчәлеген төгәлрәк чагылдырган сүзләрне әйтеп җибәрү; фикерне логик рәвештә һәм аңлаешлы итеп белдерергә ярдәм итү.
Кызыксындыруны үстерүгә булышлык итү.
Балаларга яшьтәшләре белән дустанә аралашырга ярдәм итү, дусны ни- чек итеп шатландырырга, котларга мөмкин булуын, аның гамәлләренә карата ризасызлыкны ничек итеп тыныч кына белдерергә, ничек гафу үтенергә икәнлеген әйтеп тору.
**Сүзлек формалаштыру.** Якын тирәлек турындагы белемнәрне тирәнәй- тү нигезендә балаларның сүз запасын тулыландыру һәм активлаштыру. Үз тәҗрибәләре аша таныш булмаган предметлар, күренешләр, вакыйгалар турындагы күзаллауларын киңәйтү. Сөйләмдә предметлар, аларның өлешләре, алар эшләнгән материалларның атамаларын куллануны активлаштыру.
Сөйләмдә иң күп кулланылучы сыйфатларны, фигыльләрне, рәвешләрне, бәйлекләрне файдаланырга өйрәтү.
Балалар сүзлегенә һөнәрләрне белдерүче исемнәрне, хезмәт гамәлләрен сыйфатлаучы фигыльләрне кертү.
Балаларны предметның урынын (сулда, уңда, янәшә, янында, арасында), тәүлек вакытын ачыкларга һәм билгеләргә, аларны әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү. Балалар тарафыннан еш кулланылучы күрсәтү алмашлыкларын һәм рәвешләрне (тегендә, шунда,

шундый, шушы, бу) төгәлрәк мәгънәле сүзләр белән алыштырырга булышу; антоним сүзләр куллану (чиста — пычрак, якты — караңгы).
Гомумиләштерүче мәгънәле исемнәр кулланырга өйрәтү (йорт җиһазлары, яшелчәләр, хайваннар һ.б.).
**Сөйләмнең аваз культурасы.** Сузык һәм тартык авазларны дөрес әйтүне ныгыту, сызгырулы, чыжылдаучы һәм сонор (р, л) авазларны әйтергә өйрәнү. Артикуляция аппаратын үстерү.
Дикция өстендә эшләүне дәвам итү: сүзләрне һәм сүзтезмәләрне ачык итеп әйтүне камилләштерү.
Фонематик ишетү сәләтен үстерү: билгеле бер авазга башланучы сүзләр- не яңгырашлары буенча аерырга һәм әйтергә өйрәтү.
Сөйләмнең интонация тәэсирен камилләштерү.
**Сөйләмнең грамматик төзелеше.** Балаларда җөмләдә сүзләрне яраштыру, сөйләмдә бәйлекләрне дөрес куллана белү сәләте формалаштыруны дәвам итү, хайваннарның балаларын белдерүче исемнәрнең күплек сан фор- масын ясау (аналогия буенча), бу исемнәрне баш һәм төшем килешләрендә куллану (төлке балалары — төлке балаларын, аю балалары — аю балаларын); исемнәрнең иялек килешендәге күплек сан формасын дөрес куллану (чәнечкеләрнең, алмаларның, туфлиләрнең).
Татар телендә кайбер парлы әгъзалар (күзләр, куллар, аяклар) турында берлек сандагыча сөйләшү тәртибе белән таныштыру: «күзем йомыла», «кулым туңды», «аягым арыды» һ.б.

Яшәешнең бишенче елы өчен хас сүзләр иҗат итү күренешен хуплау, әдәпле генә итеп сүзнең гомуми кабул ителгән үрнәген әйтеп җибәрү.
Балаларда сөйләмдә тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләрнең иң гади төрләрен актив куллану теләге тудыру.
**Бәйләнешле сөйләм**. Диалогик сөйләмне камилләштерү: әңгәмәдә катнашырга, тыңлаучылар өчен аңлаешлы итеп сорауларга җаваплар, сораулар бирергә өйрәтү.

[1]МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара

Балаларны сөйли белергә өйрәтү: предметны, картинаны тасвирлау, та- ратылган дидактик материалны кулланып, бала үзе ясаган картина (күренеш) буенча хикәя төзергә өйрәтү.
Балалар белән әкиятләрдән иң тәэсирле һәм хәрәкәткә бай өзекләрне сөйләп күрсәтү буенча күнегүләр уздыру

### 2.1.4. «Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе

«Сәнгати-эстетик үсеш сәнгать (сүз-тел сәнгате, музыкаль, сынлы сәнгать) әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәмаңлау алшартлары үсешен; әйләнә-тирә дөньяга карата эстетик мөнәсәбәтбарлыкка килүне; сәнгать төрләре турында элементар күзаллаулар формалашуны; музыканы, матур әдәбиятны, фольклорны аңга кабул итүне; әдәби әсәрләр пер-сонажларының кичерешләрен уртаклашуны стимуллаштыруны;балаларның мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тота».
**Төп максатлар һәм бурычлар.**
Әйләнә-тирә чынбарлыкның эстетик ягына карата кызыксынучанлык, әйләнә-тирә дөнья предметларына һәм күренешләренә, сәнгать әсәрләренәкарата эстетик мөнәсәбәтформалаштыру; нәфис-иҗади эшчәнлеккә каратакызыксынучанлык тәрбияләү.Балаларның эстетик хисләрен, сәнгати кабул итүен,образлы күзаллауларын, хыялларын,

иҗади сәләтләрен үстерү.Балалар иҗатын, мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеккә карата кызыксынуны үстерү; балаларның үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗын канәгатьләндерү.

**Сәнгатькә тарту.** Балаларда сәнгатькә тартылуны, сәнгатькә карата кызыксынуны үстерү. Халык сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәрләрен караганда, музыкаль фольклор әсәрләрен тыңлаганда эстетик хисләр, эмоцияләр ча- гылышын хуплау.
Балаларны артист, рәссам, композитор һөнәрләре белән таныштыру.
Табигатьтәге, әйләнә-тирәдәге предметларны һәм күренешләрне тану һәм әдәбият, музыка, сынлы сәнгатьтәге сәнгати образлар белән атау теләге тудыру.
Сәнгать жанрларын һәм төрләрен аерырга өйрәтү: шигырьләр, проза, табышмаклар (әдәбият), җырлар, биюләр, музыка, картина (репродукция), скульптура (сынлы сәнгать), бина һәм корылма (архитектура).

Төп тәэсир итү чараларын (төс, форма, зурлык, ритм, хәрәкәт, ишарә, аваз (тавыш)) аерырга һәм әйтә белергә, шулай ук сурәтләү, музыкаль, конструкцияләү эшчәнлегендә үз нәфис образларын тудырырга өйрәтү.
Балаларны архитектура белән таныштыру. Алар яшәгән йортларның (балалар бакчасы, мәктәп, башка биналар) архитектура корылмалары икәнлеге; йортларның форма, биеклек, озынлык, катлар һәм подъездлары исәбе, тәрәзә рәвешләре һ.б. буенча төрле булуы турында карашлар формалаштыру.
Балалар бакчасы тирәсендә урнашкан төрле корылмаларга (бала һәм аның дуслары яшәгән йортлар, мәктәп, кинотеатр) карата кызыксыну уяту.
Балаларның игътибарын төрле биналарның охшашлыгына һәм аерымлыкларына җәлеп итү, мөстәкыйль рәвештә бинаның өлешләрен, аның үзенчәлекләрен аера белүне хуплау. Форма һәм төзелеш буенча охшаш биналарда аерымлыклар (ишекләр, тәрәзәләр һәм башка өлешләрнең формасы һәм зурлыгы) күрә белүне ныгыту.
Балаларның рәсемнәрдә, аппликацияләрдә чынбарлыктагы һәм әкияти корылмаларны сурәтләү омтылышын хуплау.
Музейга баруны оештыру (әти-әниләр белән бергә), музейның төре, вази- фасы турында сөйләү.
Курчак театрына, күргәзмәләргә йөрүгә карата кызыксынуны үстерү. Балаларның китап, китап иллюстрациясе турындагы белемнәрен ныгыту. Язучылар һәм шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителгән китапларны саклау үзәге буларак, китапханә белән таныштыру. Халык иҗаты әсәрләре (мәзәкләр, әкиятләр, табышмаклар, җырлар, әйлән-бәйлән, мөрәҗәгать-такмаклар, халык гамәли-бизәлеш сәнгате эшләнмәләре) белән таныштыру.Сәнгать әсәрләренә карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Сурәтләү эшчәнлеге.** Балаларның сынлы сәнгатькә карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү. Рәсем ясау, әвәләп ясау, кисеп алу һәм ябыштыру тәкъдимнәрен эмоциональ яктан уңай кабул итү булдыру.
Эстетик кабул итү, образлы күзаллаулар, хыял, эстетик хисләр, сәнгати иҗат сәләтләре үстерүне дәвам итү.

Предметларны җентекләп карый һәм өйрәнү (шул исәптән куллар ярдәмендә дә) күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү. Иҗади үсеш нигезе буларак, балаларның сынлы сәнгать турындагы кү- заллауларын баету (балалар әдәбияты әсәрләренә иллюстрацияләр, нәкыш сәнгате әсәрләре репродукцияләре, халык бизәлеш сәнгате, кече формалы скульптура һ.б.). Рәсем ясау, әвәләп ясау, аппликациягә хас тәэсир итү чараларын аерырга һәм кулланырга өйрәтү.

Рәсем ясауда, әвәләп ясауда, аппликациядә коллектив әсәрләр иҗат итү күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү.

Рәсем ясаганда дөрес утыру: бөкрәймәү, өстәл өстенә, мольбертка таба бик түбән иелмәү; үзеңне киеренке тотмыйча, иркен утыру күнекмәләрен ныгыту. Балаларны пөхтәлеккә: үз эш урынын тәртиптә тотуга, эш беткәч барысын да өстәлдән җыеп алуга өйрәтү.

Башка балаларның эшләрен бәяләгәндә дусларча киң күңеллелек күрсәтергә өйрәтү.

**Рәсем ясау.** Балаларда аерым предметларны ясау, бер үк предметларны кабатлап (аумас курчаклар саф һавада йөриләр, кышын безнең участоктагы агачлар, чебиләр үләндә йөриләр) һәм алар янына башкаларын өстәп (кояш, кар ява һ.б.) сюжетлы композицияләр төзи белү сәләте формалаштыруны дәвам итү.

Предметларның формасы (түгәрәк, овал, квадрат, турыпочмаклык рәвешендә, өч почмаклы), өлешләрнең зурлыгы, урыны турында күзаллаулар формалаштыру һәм ныгыту.

Сюжетны чагылдырганда, балаларга сурәтләрне кәгазь битенә вакыйга эчтәлегенә һәм вакыйгага кертелгән объектларга туры китереп урнашты- рырга ярдәм итү. Балаларның игътибарын предметларның зурлык буенча чагыштырмаларына юнәлтү: агач биек, куак агачтан тәбәнәгрәк, чәчәкләр куактан тәбәнәгрәк.

Балаларның тирәлектәге предметларның һәм табигать объектларының төсләре һәм төсмерләре турындагы күзаллауларын ныгытуны һәм баетуны дәвам итү. Инде билгеле төсләргә һәм төсмерләргә яңаларын өстәү (коңгырт, кызгылт-сары, сыек яшел); бу төсләрне ничек табу мөмкинлеге турында күзаллау формалаштыру.

Тиешле төсләрне һәм төсмерләрне табу өчен буяуларны кушарга өйрәтү. Рәсем ясауда, аппликациядә төрле төсләр куллану теләген үстерү, игътибарны әйләнә-тирә дөньяның күптөрле булуына юнәлтү.

Карандаш, пумала, фломастер, төсле акбурны дөрес тоту; сурәтләр ясаганда аларны куллана белү күнекмәләрен ныгыту.

Балаларны рәсемнәрне — пумала, карандаш белән, сызыкларны һәм штрихларны бер генә юнәлештә (өстән аска яки сулдан уңга таба) сызып буярга өйрәтү; буяуны, штрихларны ритмлы хәрәкәтләр белән бөтен форма буенча, контур чикләреннән чыкмыйча төшерү; калын сызыкларны пумала- ның бар киңлеге белән, нәзек сызыкларны һәм нокталарны кыл очы белән генә төшерү. Башка төстәге буяу куллану алдыннан пумаланы чиста итеп юу тәртибен ныгыту. Ел ахырына балаларда, карандашка басымны үзгәртеп, төснең сыек һәм куе төсмерләрен таба белүне формалаштыру.

Катлаулы предметлар (курчак, куян һ.б.) рәсемнәрен ясаганда, аларның өлешләрен дөрес урнаштыра һәм бу өлешләрне үлчәм буенча яраштыра белүне формалаштыру.

**Декоратив рәсем ясау.** Дымково, Филимоново бизәкләре мотивлары буенча декоратив композицияләр ясарга өйрәтүне формалаштыруны дәвам итү. Матурлыкны эстетик кабул итүне үстерү һәм Дымково, Филимоново бизәлешләре стилендәге бизәкләр иҗат итү өчен үрнәк сыйфатында шул бизәлешләрдәге эшләнмәләрне файдалану (бизәкләү өчен балалар әвәләп ясаган уенчыклар һәм кәгазьдән кисеп алынган уенчык силуэтлары кулла- нылырга мөмкин).

Балаларны Городец эшләнмәләре белән таныштыру. Городец бизәлеше элементларын (чәчәк бөреләре, роза чәчәкләре, яфраклар) аерырга өйрәтү; бизәлештә кулланылган төсләрне аерып ала һәм атап әйтә белергә өйрәтү.

**Әвәләп ясау.** Балаларның әвәләп ясауга карата кызыксынуын үстерүне дәвам итү; балчыктан (пластилиннан, пластик массадан) әвәләп ясау күнекмәләрен камилләштерү. Моннан алдагы төркемнәрдә үзләштерелгән әвәләп ясау алымнарын ныгыту; яньчелгән шарның барлык кырыйларын чеметкәләп, аз гына тышка сузып чыгарырга, балчык кисәгенең аерым өлеш- ләрен сузып озынайтырга, вак детальләрне (мәче баласының колакларын, кошчыкның томшыгын) чеметкәләп ясарга өйрәтү. Әвәләп ясалган предметның, фигураның өслеген бармаклар белән шомартырга өйрәтү.

Куыш эчле форма булдыру өчен шарның, цилиндрның үзәген батырып эчкә кертү алымнарына өйрәтү. Стека (махсус таякчык) куллану алымнары белән таныштыру. Әвәләп ясалган эшләнмәләрне стека ярдәмендә бизәкләү омтылышын хуплау.

Пөхтә әвәләү алымнарын ныгыту.

**Аппликация.** Аппликациянең эчтәлеген катлауландырып һәм төрле сурәтләр иҗат итү мөмкинлекләрен киңәйтеп, аппликациягә карата кызыксыну тәрбияләү. Балаларда кайчыны дөрес тоту һәм аны файдалана белү күнекмәләре формалаштыру. Туры сызык буенча иң элек кыска, аннары озын буйлар кисү күнекмәсен формалаштырудан башлап, фигуралар кисеп алырга өйрәтү. Буйлардан төрле предметлар (койма, эскәмия, баскыч, агач, куак һ.б.) сурәтләрен төзергә өйрәтү. Почмакларны түгәрәкләү юлы белән квадраттан түгәрәк формалар һәм турыпочмаклыктан овал формалар кисеп алырга өйрәтү; бу алымны аппликациядә яшелчәләр, җимешләр, җиләкләр, чәчәкләр һ.б. сурәтләрен ясау өчен куллану.

Аппликациядә әзер формалардан җыелучы предметларның (чын һәм хыялдагы кошлар, хайваннар, чәчәкләр, бөҗәкләр, йортлар) санын арттыра бару. Балаларны әлеге формаларны ике яки дүрт өлешкә (түгәрәкне — ярымтүгәрәкләргә, чирекләргә; квадратны өчпочмакларга һ.б.) кисеп, үзгәртергә өйрәтү.

Пөхтә итеп кисү һәм ябыштыру күнекмәләрен ныгыту. Активлык һәм иҗадилык чагылышын хуплау.

**Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге.** Балаларда төзелеш детальләрен (куб, пластина, кечкенә кирпеч, борыс) аера һәм атап әйтә белү сәләтен үстерүне дәвам итү; аларны конструкция үзлекләрен (тотрыклылык, форма, зурлык) исәпкә алып кулланырга өйрәтү. Балаларның нинди охшаш корылмалар күрүләрен исләренә төшерергә тәкъдим итеп, ассоциатив бәйләнешләрне ачыклый белүләрен үстерү.

Корылма үрнәген анализларга өйрәтү: төп өлешләрне аерып күрсәтү, аларны зурлык һәм форма буенча аеру һәм чагыштыру, бу өлешләрнең бер-берсенә карата пространствода урнашуларын билгеләү (йортларда — стеналар, өстә — түшәм, түбә; автомобильдә-кабина, кузов һ.б.).

Корылмаларны мөстәкыйль рәвештә үлчәргә (биеклек, озынлык һәм киңлек буенча), тәрбияче тарафыннан бирелгән конструкция принцибын сакларга («Шундый ук, әмма биек йорт төзе») өйрәтү.

Эре һәм вак төзелеш материалларыннан корылмалар төзергә, корылмаларны төзү һәм бизәү өчен төрле төстәге детальләр кулланырга өйрәтү.

Кәгазьдән конструкцияләүгә өйрәтү: якларын һәм почмакларын бер-берсенә тәңгәлләштереп, туры почмаклы кәгазь битен урталай бөкләү (альбом, участокны бизәү өчен флаглар, котлау открыткасы), төп формага детальләр (йортка— тәрәзәләр, ишекләр, морҗа; автобуска— көпчәкләр; урындыкка— җилкә терәге) ябыштыру.
Корылмаларны мөстәкыйль рәвештә үлчәргә (биеклек, озынлык һәм киңлек буенча), тәрбияче тарафыннан бирелгән конструкция принцибын сакларга («Шундый ук, әмма биек йорт төзе») өйрәтү.
Эре һәм вак төзелеш материалларыннан корылмалар төзергә, корылмаларны төзү һәм бизәү өчен төрле төстәге детальләр кулланырга өйрәтү.
Кәгазьдән конструкцияләүгә өйрәтү: якларын һәм почмакларын бер-берсенә тәңгәлләштереп, туры почмаклы кәгазь битен урталай бөкләү (альбом, участокны бизәү өчен флаглар, котлау открыткасы), төп формага детальләр (йортка— тәрәзәләр, ишекләр, морҗа; автобуска— көпчәкләр; урындыкка— җилкә терәге) ябыштыру.
Балаларны табигый материаллардан: кайрыдан, ботаклардан, яфраклардан, күркәләрдән, каштаннардан, чикләвек кабыгыннан, саламнан әйберләр (көймәләр, керпеләр һ.б.) ясарга тарту. Өлешләрне беркетү өчен җилем, пластилиннан файдаланырга, әйберләр ясаганда кәтүкләр, төрле зурлыктагы тартмалар һ.б. кулланырга өйрәтү.

**Музыкаль эшчәнлек.** Балаларда музыкага карата кызыксыну, аны тыңлау теләге тәрбияләү, музыкаль әсәрләрне хис аша кабул итү тәрбияләү. Музыкаль тәэсирләрне баету, музыка культурасы нигезләрен алга таба үстерүгә булышлык итү.
**Тыңлау.** Музыканы тыңлау культурасы (игътибарны башка нәрсәгә юнәлтмәү, әсәрне ахырынача тыңлап бетерү) күнекмәләре формалаштыру.
Музыканың характерын тоемларга, таныш әсәрләрне танып алырга, тыңланган әсәрдән туган тәэсирләреңне белдерергә өйрәтү.
Музыкаль әсәрнең тәэсир итү чараларын тоярга өйрәтү: акрын, көчле, салмак, тиз. Авазларны югарылык буенча аеру сәләтен үстерү (секста, септима чикләре эчендә югары, түбән).
**Җырлау.** Балаларны тәэсирле итеп җырларга өйрәтү, сузып, хәрәкәтчән, бертавышка (беренче октавадагы ре — си чикләре эчендә) җырлый белү күнекмәләре формалаштыру. Кыска музыкаль фразалар арасында тын алуны камилләштерү. Көйне чиста җырларга, фразалар ахырын йомшартырга, сүзләрне ачык итеп әйтергә, музыканың характерын чагылдырып, тәэсирле итеп җырларга өйрәтү. Музыка уен коралларына кушылып һәм алардан башка җырларга өйрәтү (тәрбияче ярдәмендә).
**Җыр иҗаты.** Бишек җыры көен мөстәкыйль иҗат итәргә һәм көйләп би- релгән сорауларга («Синең исемең ничек?», «Пескәй, сиңа ни кирәк?», «Син кайда?») җавап бирергә өйрәтү. Бирелгән текстка импровизация белән көй чыгару сәләте формалаштыру.

**Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр.** Балаларда музыка характерына тәңгәл рәвештә ритмик хәрәкәтләнү күнекмәсе формалаштыруны дәвам итү.
Музыканың ике яки өч кисәкле формасына карап, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләрне үзгәртергә өйрәтү.
Бию хәрәкәтләрен камилләштерү: туры галоп, «пружинка», ялгыз һәм парлашып бөтерелү.

Балаларны биюләрдә һәм әйлән-бәйләндә, һәм парлап биегәндә түгәрәк буенча хәрәкәт итәргә, аяк очына һәм үкчәгә басарга, кулларны ритмик чәбәкләргә, иң гади төрдәге башкача хәрәкәтләрне (түгәрәктән чыгып си- белү һәм кабат түгәрәккә басу), сикереп алуларны башкарырга өйрәтү.
Балаларда төп хәрәкәтләр (йөрү: «тантаналы», тыныч, «серле»; йөгерү: җиңелчә, ашкынулы) күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү.
**Бию-уен иҗаты.** Мимика һәм пантомима (шат һәм боек куян, хәйләкәр төл- ке, ачулы бүре һ.б.) кулланып, музыка-уен күнегүләрен (яфрак бөтерелә, кар бөртекләре төшә) эмоциональ-образлы башкаруны үстерүгә булышлык итү.
Җырларны сәхнәләштерергә һәм кечерәк музыкаль спектакльләр куярга өйрәтү.
**Балалар музыка уен коралларында уйнау.** Иң гади көйләрне агач кашыклар, шалтыравыклар, барабан, металлофон кулланып уйнау күнекмәләре формалаштыру.

**Психологик-педагогик эш эчтәлеге**

Балаларны кеше гәүдәсенең төрле өлешләре һәм сизү органнары белән таныштыруны дәвам итү.
Кеше тормышы һәм сәламәтлеге өчен гәүдә өлешләренең һәм сизү органнарының әһәмияте турында күзаллау формалаштыру (куллар күп кенә файдалы эшләр эшли; аяклар хәрәкәтләнергә ярдәм итә; авыз сөйли, ашый; тешләр чәйни, тел чәйнәргә, сөйләргә ярдәм итә; тире тоя; борын сулый, ис- ләрне сизә; колаклар ишетә).
Туклану режимын үтәү, туклану өчен яшелчәләр һәм җимешләр, башка файдалы ризыклар куллану ихтыяҗы тәрбияләү.
Кеше өчен кирәкле матдәләр һәм витаминнар турында күзаллау формалаштыру. Сәламәтлек өчен йокының, гигиена процедураларының, хәрәкәтләрнең, чыныгуның мөһимлеге турындагы күзаллауларны киңәйтү.
Балаларны «сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре белән таныштыру. Бала башкарган эшнең аның сәламәтлегенә йогынты ясавын аңларга өйрәтү («Мин тешләремне чистартам — димәк, алар ныклы һәм сәламәт булачак», «Мин урамда аякларымны чылаттым, һәм миңа салкын тиде».
Бәрелгәндә үз-үзеңә элементар ярдәм күрсәтү, авырганда, имгәнгәндә ярдәм сорап өлкәннәргә мөрәҗәгать итү күнекмәләре формалаштыру.
Сәламәт яшәү рәвеше; кеше организмы өчен физик күнегүләрнең әһәмия- те турында күзаллаулар формалаштыру.
Организмның төрле органнарын һәм системаларын ныгыту өчен физик күнегүләр белән таныштыруны дәвам итү.

**2.1.5. “Физик үсеш” белем бирү өлкәсе**

«Физик үсеш балалар эшчәнлегенең түбәндәге төрләрендә тәҗрибә булдыруны үз эченә ала: хәрәкәтләнү, шул исәптән координация һәм сыгылмалылык кебек физик сыйфатларны үстерүгә юнәлтелгән, организмның терәкхәрәкәт системасын дөрес формалаштыруга, тигезлек саклауга, хәрәкәтнекоординацияләүгә, кулларның эре һәм вак моторикасына булышлык итүче,шулай ук төп хәрәкәтләре дөрес һәм организмга зыян салмаслык итеп башкарылган атлап йөрү, йөгерү, җиңелчә сикерүләр, ике якка да борылулар кебек күнегүләрне эшләү белән бәйле хәрәкәт эшчәнлеге; спортның кайбер

төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалашу; кагыйдәләре беләнбергә хәрәкәтчел уеннарны үзләштерү; хәрәкәтләнү өлкәсендә максатчалык һәм үз-үзеңне көйләү формалашу; сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләреформалашу, шул яшәү рәвешенең элементар нормаларын һәм кагыйдәләренүзләштерү (туклануда, хәрәкәтләнү режимында, чыныгуда, файдалы гадәтләр формалаштыруда һ.б.»[1].

**Төп максатлар һәм бурычлар**

**Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.**

Балаларда сәламәт яшәү турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.

**Физик культура.** Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту; акыл һәмфизик мөмкинлекләрен арттыру, талчыгуны искәртү.Гармонияле физик үсешне тәэмин итү, төп хәрәкәт төрләрендә сәләт һәмкүнекмәләрне камилләштерү, хәрәкәтләрнең матурлыгына, нәзакәтлелегенә, тәэсирлелегенә ирешү, гәүдәнең дөрес тотышын формалаштыру.Көндәлек хәрәкәтләнү эшчәнлеге ихтыяҗы формалаштыру. Хәрәкәтләнү эшчәнлегендә инициативалылык, мөстәкыйльлек һәм иҗат, үз-үзеңне контрольдә тоту, хәрәкәтләр башкарганда үз-үзеңне бәяләү сыйфатларынүстерү.Хәрәкәтле уеннарда һәм спорт уеннарында, физик күнегүләрдә катнашуга карата кызыксынуны, мөстәкыйль хәрәкәтләнү эшчәнлегендә активлыкны үстерү; спортка карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

Балаларда кешенең тормышы һәм эшчәнлеге өчен төрле органнарныңәһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру: күзләр — күрер өчен, колаклар — ишетер өчен, борын — ис тояр өчен, тел — тәмне татыр өчен, куллар — эләктерер, тотар, кагылу өчен; аяклар — басып тору, сикерү, йөгерү,йөрү өчен; баш — уйлар, хәтердә калдырыр өчен. Гәүдәнең тотрыклы халәтен, дөрес торышын саклый белү күнекмәләре

формалаштыру.Куллар һәм аякларны үзара көйле, иркен хәрәкәт иттереп, бер-береңә

бәрелмичә йөрергә һәм йөгерергә өйрәтү. Күрү ориентирларына таянып,билгеле бер юнәлеш буенча бергәләп хәрәкәт итәргә, барганда һәм йөгергәндә, педагог күрсәтмәсе буенча, хәрәкәт итүнең юнәлешен һәм рәвешенүзгәртергә өйрәтү.

Шуышырга, үрмәләргә, туп белән төрлечә эш итәргә (тотып алу, тотыптору, күчерү, кую, ыргыту, тәгәрәтү) өйрәтү. Алга хәрәкәт ясап, ике аяк беләнурында сикерергә, ике аяк белән урыннан этелеп озынлыкка сикерергә өйрәтү.

**Хәрәкәтле уеннар**. Балаларда тәрбияче белән бергәләп гади эчтәлекле,катлаулы булмаган хәрәкәтле уеннар уйнау теләге үстерү. Балаларның төпхәрәкәтләрне (йөрү, йөгерү, ыргыту, тәгәрәтү) камилләштерә торган уеннаруйнау күнекмәләре үсешенә булышлык итү. Хәрәкәтләрнең тәэсирлелегенә, кайбер персонажларның иң гади гамәлләрен чагылдыра белергә (куян балалары кебек сикерү; чебиләр кебек бөртекләр чүпләү һәм су эчү һ.б.) өйрәтү.

**2.1.6.Милли мәдәни төбәк чыганагы (ЭРС)**

| **Татарская** | **Русская** |
| --- | --- |
| **Ознакомление с культурой народов Поволжья** | |
| **1.** Куклы в татарской и русской национальной одежде (мальчик и | **1.**Куклы в татарской и русской национальной одежде |

| | |
|---|---|
| девочка). | (мальчик и девочка). |
| **2.**Материал о родном городе<br>(6-7 иллюстрации). | **2.** Материал о родном городе<br>(6-7 иллюстрации). |
| **3.** Информационный и наглядный материал о родном крае (животный, растительный мир). | **3.** Информационный и наглядный материал о родном крае (животный, растительный мир). |
| **4.** Информационный материал о России. Иллюстративный материал о Москве.<br>(образцы орнаментов татарского и русского народа для ИЗО деятельности, дидактические, подвижные игры). | **4.** Информационный материал о Татарстане, России. Иллюстративный материал о Москве.<br>(образцы орнаментов татарского и русского народа для ИЗО деятельности, дидактические, подвижные игры). |
| **5.** Художественная литература на родном языке, содержание которой соответствует возрастным особенностям детей. | **5.** Художественная литература (перевод татарских народных сказок и произведений татарских писателей). |
| **6.** Иллюстрации к татарским, русским народным сказкам и произведениям писателей. | **6.** Иллюстрации к татарским, русским народным сказкам и произведениям писателей. |
| **7.** Портреты татарских детских писателей по программе: Г. Тукай, А. Алиш, М. Җәлил һ. б. | **7.** Портрет Г. Тукая. |
| **8.** Образцы татарских национальных орнаментов 3 элемента:<br>- тюльпан – лалә<br>- лист – яфрак<br>- колокольчик – кыңгырау. | **8.** Образцы татарских национальных орнаментов 3 элемента:<br>- тюльпан – лалә<br>- лист – яфрак<br>- колокольчик – кыңгырау. |
| **9.** Дидактические игры по ознакомлению с элементами национального орнамента (3 игры). | **9.** Дидактические игры по ознакомлению с элементами национального орнамента (3 игры), например:<br>1. «Составь узор на салфетке»<br>2. «Найди пару» (орнаменты домино)<br>3. «Найди и назови» (орнамент). |
| **10.** Шаблоны и трафареты. | **10.** Шаблоны и трафареты. |
| **Закрепление пройденного материала УМК** | |
| **Материалы**<br>по обучению детей татарской национальности родному языку – **УМК для детей 4-5 лет “Туган телдә сөйләшәбез”** (Говорим на родном языке), Хазратова Ф.В., Шарафутдинова З.Г., Хабибуллина И. Җ. | **Материалы**<br>по обучению русскоязычных детей татарскому языку – **УМК для детей 4-5 лет “Татарча сөйләшәбез”** (Говорим по- татарски), Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г., Исаева Р. С.и др. |
| 1. CD – диск «Туган телдә сөйләшәбез» 4-5 лет. | 1. CD – диск «Татарча сөйләшәбез» к проекту «Минем өем» - |

| | |
|---|---|
| | «Мой дом». |
| 2. Иллюстрации, картины к УМК. | 2. Предметные картины к проекту «Минем өем» - «Мой дом». |
| 3. Дидактические, словесные, ИКТ- игры (разработанные педагогами) по УМК. | 3. Дидактические, словесные, ИКТ- игры (разработанные педагогами) к проекту «Минем өем» - «Мой дом». |
| 4. Рабочие тетради для детей 4-5 лет. | 4. Рабочие тетради для детей 4-5 лет |
| | 5. Анимационные сюжеты к проекту «Минем өем» - «Мой дом». |
| **Материалы**<br>по обучению детей татарской национальности русскому языку – **УМК для детей 4-5 лет "Изучаем русский язык" ГаффароваС.М.** | |
| 1. Иллюстрации, картины к УМК. | |
| 2. Дидактические, словесные, ИКТ- игры (разработанные педагогами) по УМК. | |
| 3. Рабочие тетради для детей 4-5 лет. | |

[1] МББ ФДББСның 2.6. пунктын кара.

## 2.2. Программаны тормышка ашыру ысуллары һәм юллары

Үсешкә китерүче һәм бала өчен эмоциональ яктан уңайлы белем бирү мохите тудыру «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыруның мөһим шарты булып тора. Балалар бакчасында булу балага шатлык китерергә, ә белем бирү ситуацияләре мавыктыргыч булырга тиеш.

Иң мөһим белем бирү ориентирлары:

• балаларның эмоциональ иминлеген тәэмин итү;

• балаларның башка кешеләргә карата дустанә һәм игътибарлы мөнәсәбәтен формалаштыру өчен шартлар тудыру;

• балалар мөстәкыйльлеген (инициативалылыкны, автономия һәм җаваплылыкны) үстерү;

• балаларның эшчәнлекнең төрле төрләрендә формалашучы сәләтләренүстерү.

Әлеге максатларны гамәлгә ашыру өчен педагогларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

• бала шәхесенә карата ихтирам күрсәтү, аның белән һәм башка педагоглар белән үзара мөнәсәбәтләрнең демократик стилен үстерү;

• баланың үз өстенә җаваплылык алу һәм башка кешеләргә карата үз итүхисләрен белдерү өчен шартлар тудыру;

• килеп туган низагларны балалар белән бергә тикшерү, аларны хәл итәргә булышу, гомуми кагыйдәләр булдыру, бер-береңә карата ихтирам күрсәтергә өйрәтү;

• балалар белән тормышның мөһим мәсьәләләрен тикшерү, баланың үзпозициясен белдерүен стимуллаштыру;

• балаларның игътибарын кешеләрнең үз карашлары һәм кыйммәтләребуенча бер-берсеннән аерылып торуларына юнәлтү, моның аларның үз-үзләрен тотышына ничек йогынты ясавын тикшерү;

• ата-аналар (законлы вәкилләр) белән Оешма педагогларының эшчәнлеге юнәлтелгән, шул эшчәнлек ирешергә тиешле ориентирларны тикшерү,гаилә әгъзаларын әлегемаксатларга ирешү буенча бергәләп эш итүгә тарту.

Мәгариф оешмасында мәктәпкәчә белем бирү системасы баланың уеныһәм танып белү активлыгы үсешенә төбәлгән булырга тиеш. Оешмада инициативалылык, күңел күтәренкелеге, кызыксынучанлык һәм яңаны белүомтылышы кебек сыйфатлар чагылсын өчен шартлар тудырылырга тиеш.

Белем бирү мохитен дөрес оештыру үз-үзеңә ышаныч, тормышка карата оптимистик караш үсешен стимуллаштыра, ялгышуга хокук бирә, танып белү мәнфәгатьләренформалаштыра, хезмәттәшлек итәргә әзер булуныһәм башка кешегә авыр хәлдә ярдәм итүне хуплый, ягъни баланың уңышлырәвештә социальләшүен һәм аның шәхесе үсешен тәэмин итә.

Балалар тарафыннан өйрәнелүче темалар белем бирү эшенең максатларына — баланың сәләтләрен һәм инициативасын үстерүгә, мәктәпкәчә яшьтәге балага аңлаешлы мәдәни чараларны (күрсәтмә модельләрне һәм символларны) үзләштерүгә ирешү өчен материал булып тора. Шунлыктан белеем бирү программасы гомер буе барачак укуөйрәнү сәләте булдыруны, шул ук вакытта чынбарлыкка карата аңлы һәм иҗади мөнәсәбәттә булуны таләп иткән хәзерге җәмгыятьтә балаларны тормышка әзерләүнең нигезенә әверелә.

Балалар бакчасында балага яхшы таныш көн дә кабатлана торган хәлләр тәрбия-белем бирү әһәмиятенә ия: һавада йөргәндә һәм режим моментлары вакытында бала үзенә һәм башкаларга карата мөнәсәбәтләр булдыра,инициативалы булырга һәм карарлар кабул итәргә, үзенең фикерләвен һәмхыялын файдаланырга өйрәнә.

Белем бирү ситуацияләрен тәкъдим итү;

• балалар автономиясен хуплау: балаларга үз проект чишелешләрен күрсәтергә тәкъдим итү;
• үз ниятләрен башкарганда балаларга үз эшчәнлекләрен планлаштырырга ярдәм итү;
• балалар тарафыннан тәкъдим ителгән проект чишелешләрен тикшергәндә, күрсәтелгән һәр вариантның яңалыгына басым ясап, аларныңидеяләрен хуплау;
• балаларга алар тарафыннан тәкъдим ителгән чишелеш вариантларынчагыштырырга, вариантны сайлауны нигезләргә булышу.

### 2.2.1.Гаилә белән узара аралашу.

Гаилә белән конструктив бәйләнешләр үстерү бала шәхесенең тулы үсешен тәэмин итүнең иң мөһим шарты булып тора.

Төп максат — тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы үзарамөнәсәбәтләр формалаштыру һәм ата-аналарның компетентлыгын (балатәрбияләү белән бәйле төрле типтагы социаль-педагогик ситуацияләрне хәл итә алу сәләтен) үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру; ата-аналарныңихтирамлы һәм аңлаулы мөнәсәбәткә, балалар бакчасы тормышында катнашуга хокукын тәэмин итү.

Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә үзара мөнәсәбәтләрдә субординациядән, монологизмнан арыну, бер-берләрен гаепләү гадәтеннән баш тарту,бер-берләрен үз проблемаларын хәл итү чарасы итеп түгел, ә тигез хокуклыпартнерлар, хезмәттәшләр итеп күрә белү зарур.

Балалар бакчасының гаилә белән багланышларының төп бурычлары:

• педагогларның һәм ата-аналарның балаларны тәрбияләү, өйрәтү-укыту,үсешләренә ирешү, балалар бакчасында һәм гаиләдә төрле эшчәнлекне оештыру шартларына кагылышлы төрле мәсьәләләргә карата мөнәсәбәтләрен өйрәтү;

• педагогларны һәм ата-аналарны балалар бакчасында һәм гаиләдә тәрбияләүнең иң отышлы тәҗрибәсе, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларныгаиләдә һәм җәмгыятьтә тәрбияләүдә туган кыенлыклар белән таныштыру;

• балаларны тәрбияләүнең һәм өйрәтү-укытуның актуаль мәсьәләләре,балалар бакчасының һәм гаиләнең әлеге мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлекләре турында бер-берләренә җиткереп тору.

• балалар бакчасында педагогларның һәм ата-аналарның балалар беләнүзара конструктив тәэсир итешүе үсешенә булышлык итүче, эчтәлеге һәмформасы буенча төрле булган хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру;

• тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен районда (шәһәрдә, өлкәдә, республикада) оештырыла торган, педагоглар белән бергә уздырылучы чаралардакатнашуга җәлеп итү;

• баланың төрле омтылышларына һәм ихтыяҗларына карата игътибарлы мөнәсәбәт күрсәткән ата-аналарны хуплау, әлеге ихтыяҗларны гаиләдә канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру.

**Ата-аналар белән бердәм эшчәнлек**

| **Эш төре** | **Эчтәлеге** | **Җаваплы** |
|---|---|---|
| | **Сентябрь.** | |
| 1.Әти-әниләр турында мәгълүматлар туплау. | | Тәрбиячеләр. |
| 2.Әти-әниләрне антропометрик күрсәткечләр белән таныштыру. | I кварталда балаларның буйларын, авырлыкларын үлчәү. | Шәфкать туташы, тәрбиячеләр. |
| 3. Ширма “Алтын көз килде” | Көзге табигатьне сүрәтләнгән рәсемнәр, шигырьләр, уеннар. | Тәрбиячеләр. |
| 4.Ширма :<br>Тема: “Куркынычсызлык кагыйдәләрен беләбезме?” | Ата-аналарны куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру. | Тәрбиячеләр. |
| 5. Туган көн почмагы. | Балаларның туган көн бәйрәмен уздыру. | Тәрбиячеләр |
| 6. Ата-аналарга белешмәлек тарату.<br>Тема: “Әти-әни мине саклагыз” | Бу юнәлештәге эшнең әһәмиятен аңлату. | Тәрбиячеләр. |

| | | |
|---|---|---|
| 7.Әти-әниләр җыелышын уздыру.<br>Тема: “4-5 яшьлек балаларның психологик үзенчәлекләре, белем һәм тәрбия бирү программасы таләпләре” | Көн тәртибе:<br>1. Рус теле, физик культура җитәкчеләре бн танышу.<br>2. “4-5 яшьлек балаларның психологик үзенчәлекләре, белем һәм тәрбия бирү бурычлары бн таныштыру”<br>3. Анкета тутыру.<br>4. Әти-әниләр советын сайлау.<br>5. Төрлесеннән. | Тәрбиячеләр<br>Рус теле, физик культура, инглиз теле җитәкчеләре бн танышу. |
| 8. Консультация: “ Нәрсә ул терроризм?” | Терроризм буенча күзаллау булдыру | Тәрбиячеләр. |
| | **Октябрь** | |
| 1. Күчермә папка: “Уйный – уйный өйрәнәбез”. | Уен төрләре белән таныштыру. Бала белән уйнап булган уеннарның үрнәкләрен тәкъдим итү. | Тәрбиячеләр |
| 2. Әңгәмә: “Күмәк эшчәнлек” | Максат: ата-ана һәм баланың күмәк эшчәнлеге һәм аның тәрбияви чара буларак әһәмиятен аңлату. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 3.Әңгәмә:”Бала бакчадан уенчык алып кайта?” | Бу очракта балага җәза бирү кирәкме ? Әллә инде уртага салып сөйләшү уңай нәтиҗә бирәме ? | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 4.Күргәзмә “Көз күчтәнәчләре” | Күргәзмә ясау. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 5."Яхшы сүз - җан азыгы"<br>Әби - бабайларны бәйрәм бн котлау | Өлкәннәрне бәйрәм белән котлап ширма ясау. | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| | **Ноябрь** | |
| 1.Консультация. Тема: “Балагызны беләсезме?” | Күзәтүләрдән чыгып әти-әниләр белән аерым сөйләшү. | Тәрбиячеләр. |
| 2.Әниләр көненә багышланган спорт бәйрәме | Рәсемнәрдән күргәзмә ясау. | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе, әти-әниләр. |
| 3.“Минем хокукларым” исемле альбом тәкъдим итү. | 20 ноябрь – Бала хокукларын яклау көне.<br>Һәр бала гаиләгә хокуклы, бала тәрбияләүдә әти-әни җавап-лы, ә балалар үз чиратларында аларның сүзләрен тыңларга, ярдәм итәргә, ихтирам итәргә тиешлекне аңлату (Конвенция,9 нчы ст.) | Тәрбиячеләр. |

| | | |
|---|---|---|
| 4.Ширма. Тема: “Бәйрәм белән әниләр” котлау сүзе. | Әниләрне бәйрәм белән котлап ширма ясау. | Тәрбиячеләр. |
| | **Декабрь.** | |
| 1.Әти-әниләрне антропометрик күрсәткечләр белән таныштыру. | II кварталда балаларның буйларын, авырлыкларын үлчәү. | Шәфкать туташы, тәрбиячеләр. |
| 2. Кышкы сыннар. | Уен мәйданчыгын кышка бизәү. | Тәрбиячеләр. |
| 3.”Хуш киләсең, Яңа ел!” бәйрәм иртәсенә костюмнар әзерләү. | Әти-әниләрне яңа елга костюмнар тегәргә тарту. | Әти-әниләр, тәрбиячеләр. |
| 4.”Яңа ел”га багышлап группа бүлмәсен бизәү. | Әти-әниләрне бәйрәмгә, бүлмә бизәүгә, уенчыклар ясарга җәлеп итү. | Тәрбиячеләр, тәрбияче ярдәмчеләре, әти-әниләр. |
| 5. Күчермә папка:<br>“Коррупциягә каршы”. | Әти-әниләрне коррупциягә каршы көрәш юллары белән таныштыру. | Тәрбиячеләр |
| 6.Консультация. Тема: “Балаларны дөрес итеп киендерик” | Кыш көне балаларны киендерү тәртибе белән таныштыру. | Тәрбиячеләр. |
| 7. Бәйрәм иртәсе уздыру. | Балалар белән яңа ел бәйрәмен үткәрү. | Музыка җитәкчесе, тәрбиячеләр. |
| | **Январь** | |
| 1.Әти-әниләр җыелышы<br>Тема: “Хезмәт төбе хөрмәт” | Максат: Балаларда әти-әни профессиясенә кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. Гаиләдә балага беренче хезмәт күнекмәләре бирүдә әти-әнинең роле.<br>Көн тәртибендә:<br>1.”Балагызга беренче хезмәт күнекмәләрен ничек бирәсез?”<br>(анкета нәтиҗәләре буенча әңгәмә).<br>2.”Гаиләдә хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү алымнары”<br>.<br>3.”Гаиләдә бала белән бердәм хезмәт оештыру алымнары”<br>(гаиләдәге алдынгы тәҗрибәне өйрәнеп фикер алышу).<br>4.Төрлесеннән.<br>5.Белешмәлек тарату. | Тәрбиячеләр. |

| | | |
|---|---|---|
| 2. Ширма<br>“Уен аша өйрәнәбез” | УМКаның “Үстерелешле уеннар” методик кулланмасы белән таныштыру.Әти-әниләргә шушы кулланмада тәкъдим ителгән уеннарны күрсәтү һәм өйдә дә балалар белән берлектә уйнарга киңәш итү. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 3. Ширма “Зимушка-зима” | Кышкы табигатьне сүрәтләнгән рәсемнәр, шигырьләр, уеннар тәкъдим итү. | Тәрбиячеләр. |
| 4.Әти-әниләргә белешмәлек тарату. | “Чыныктыру чаралары”. | Тәрбиячеләр, шәфкать туташы |
| 5. Консультация “Кышкы уеннар”. | Саф һавада хәрәкәтле уеннарның әһәмияте. | Физкультура җитәкчесе. |
| 6.Күргәзмә “Юл тәртип ярата”. | Кул эшләренә күргәзмә. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| | **Февраль.** | |
| 1. Әңгәмә: “Җыйнаклык-күркәм гадәт”. | Җыйнаклыкка өйрәтүне мөмкин кадәр иртә башлау зарурлыгы, бала үзе башкара алган күнекмәләрне үтәргә ирек бирү, җыйнаклыкка өйрәткәндә баланы кызыксындыра торган ысуллар куллану турында аңлату. | Тәрбиячеләр. |
| 2. Әти-әниләрне халык уеннары белән таныштыру. | Әти-әниләрне бу яшьтәге балалар өчен булган халык уеннары белән таныштыру. | Тәрбиячеләр. |
| 3. Ширма “Ватанны саклаучылар көненә” котлау сузе. | Бабайларны, әтиләрне котлап ширма ясау. | Тәрбиячеләр. |
| 4. Консультация. Тема: “Өйгә кайтканда” | Әти-әниләрнең бакчадан кайтканда балаларының бакча тормышы турындагы белемнәрен киңәйтү. | Тэрбиячелэр |
| | **Март.** | |
| 1.Әти-әниләрне антропометрик күрсәткечләр белән таныштыру. | III кварталда балаларның буйларын, авырлыкларын үлчәү. | Шәфкать туташы, тәрбиячеләр. |
| 2. Ширма “Әнием-кадерлем” котлау сузе. | Әниләрне бәйрәм белән котлап ширма ясау. | Тәрбиячеләр. |
| 3. Бәйрәм иртәсен үткәрү : “Тату гаилә” | Балалар һәм әти-әниләр бн берлектә бәйрәм кичәсен үткәрү. | Тәрбиячеләр,әти-әниләр. |
| 4.Әңгәмә: “Тизәйткеч – телебезне төзәйткеч | Телдәге кимчелекләр баланың акыл үсешен тоткарлавына, фикер йөртүенә комачаулавы хакында сөйләшү. | Тэрбиячелэр. |

| | | |
|---|---|---|
| 5.Помидор, борыч, чәчәк үсентеләре өчен балчык әзерләү, орлыклар чәчү. | Әти-әниләрне кумәк эшкә тарту. | Тәрбиячеләр, тәрбияче ярдәмчеләре, әти-әниләр. |
| 6. Нәүрүз бәйрәмен уздыру**.** | Балалар белән нәүрүз бәйрәмен уздыру. | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе. |
| | **Апрель.** | |
| 1.Әти-әниләр җыелышы<br>Тема: "Баланың сәламәтлеге безнең кулларда" | Көн тәртибе<br>1. Шәфкать туташы чыгышы.<br>2. "Балаларның сәламәтлеген ныгыту алымнары буенча киңәшләр" ( тәрбияче чыгышы) Әти-әниләр бн уеннар уйнау<br>3. Белешмәлек тарату.<br>4. Төрлесеннән. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 2.Төркем бүлмәсенә гөлләр утырту өчен гөл үсентеләре алып килү. | Әти-әниләрне матурлыкка тарту, гөл үсентеләре сорау. | Тәрбиячеләр, тәрбияче ярдәмчеләре, әти-әниләр. |
| 3.Карга боткасы бәйрәмен уздыру.(**МРК)** | Балалар белән бәйрәмне уздыру. | Тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе. |
| 4. Әти-әниләр катнашындагы кул эшләреннән күргәзмә (Тукай әсәрләре буенча). | Әти-әниләрне кул эшләренә тарту. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 5. Ширма."Яз,яз,яз җитә " | Язгы табигатьне сурәтләнгән рәсемнәр, шигырьләр, уеннар тәкъдим итү.(**УМК,МРК)** | Тәрбиячеләр. |
| | **Май.** | |
| 1.Әңгәмә "Балаларыбызны саклыйк" | Җәйге чорга әти-әниләргә инструктаж уздыру | Тәрбиячеләр |
| 2.Түтәлләрне казу, тырмалау, аларга орлыклар чәчү, үсентеләр утырту. | | Тәрбиячеләр, тәрбияче ярдәмчеләре. |
| 3.Участок верандасын бизәү өчен вертушкалар ясау. | | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| 4. Сабантуй бәйрәмен уздыру. | Балалар белән сабантуй бәйрәмен уздыру. | Тәрбиячеләр, әти-әниләр. |
| | | |

## III. Оештыру бүлеге.

### 3.1. Уртанчылар төркемендә көндәлек режим

| Режимные моменты | Время/Вакыты | Режим моментлары |
|---|---|---|
| Приход детей в детский сад, игры, самостоятельная деятельность | 7.00 -7.50 | Балалар бакчасына килү,балаларны кабул итү, уеннар, мөстәкыйль эшчэнлек |
| Утренняя гимнастика | 7.50-8.00 | Иртәнге гимнастика |
| Гигиенические процедуры, подготовка к завтраку, завтрак | 8.00-8.45 | Гигиена процедуралары,иртәнге ашка хәзерлек, иртәнге аш |
| Игры, самостоятельная деятельность | 8.45-9.00 | Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек |
| Организованная образовательная деятельность, занятия со специалистами | 9.00-10.05 | Оештырылган белем бирү эшчәнлекләре |
| 1 НОД | 9.00-9.20(пн.,ср.,чт.,пт.,) | |
| перерыв | 9.20-9.30 | Тәнәфес |
| | 9.15-9.35 (вт) | |
| 2 НОД | 9.30-9.50 ( пн, ср.)<br>9.45-10.05<br>(вт.,чт.,пт. ) | |
| 2-ой завтрак | 10.05 -10.10 | Икенче аш |
| Подготовка к прогулке, прогулка, возвращение с прогулки | 10.10- 11.40 | Саф һавага әзерлек, һавада булу, саф һавадан керү |
| Самостоятельная деятельность,подготовка к обеду,обед | 11.40-12.30 | Урамнан керү, уеннар, мөстәкыйль эшчэнлек |
| Подготовка ко сну, дневной сон | 12.30-15.00 | Көндезге йокыга әзерлек, көндезге йокы |
| Постепенный подъем, воздушные, водные процедуры, самостоятельная деятельность,гигиенические процедуры | 15.00-15.20 | Йокыдан тору, һава, су процедуралары, мөстәкыйль эшчәнлек |
| Подготовка к полднику, полдник | 15.20-15.35 | Кичке ашка әзерлек, кичке аш |
| Игры, чтение художественной литературы, самостоятельная, организованная образовательная деятельность, ручной труд | 15.35-16.30 | Уеннар,матур әдәбият уку, мөстәкыйль эшчәнлек<br>кул хезмәте |
| Самостоятельная деятельность, игры на прогулки, уход детей домой | 16.30-17.30 | Мөстәкыйль эшчәнлек, уеннар. Балаларны өйләренә озату |

**3.2.Уртанчылар төркемендә 2022-2023 уку елына белем бирү эшчәнлеге челтәре.**

| | | |
|---|---|---|
| **Понедельник**<br>**Русский язык**<br>(режимный момент)<br>1. О.о «Познавательное развитие»<br>**Формирование элементарных математических представлении**<br>2. О.о. «Художественно - эстетическое развитие»<br>**Музыка**<br>**Кружок "Юный эколог"**<br>(режимный момент)<br>I подруппа | 8.40 - 9.00<br>9.00 - 9.20<br>9.30 – 9.50<br>15.35-15.55 | **Дүшәмбе**<br>**Рус теле**<br>(режим вакытында)<br>1. .Б.Ө. “Танып-белү үсеше”.<br>**Элементар математик күзаллаулар формалаштыру**<br>2.Б.Ө“Сәнгати – эстетик үсеш”<br>**Музыка**<br>**"Яшь эколог" түгәрәге**<br>(режим вакытында)<br>I подруппа |
| **Вторник**<br>**«Enjoy English»**<br>(режимный момент)<br>1. О.о. «Физическое развитие»<br>**Физкультура**<br>2.О.о. «Речевое развитие»<br>**Развитие речи**<br>**Русский язык**<br>(режимный момент) | 8.40-9.00<br>9.15-09.35<br>9.45-10.05<br>15.35-15.55 (1 подг.)<br>16.05-16.25 (2 подг.) | **Сишәмбе**<br>**«Enjoy English»**<br>(режим вакытында)<br>1.Б.Ө. “Физик үсеш”<br>**Физкультура**<br>2. Б.Ө. ”Сөйләм үсеше”<br>**Сөйләм телен үстерү**<br>**Рус теле**<br>(режим вакытында) |
| **Среда**<br>**Русский язык**<br>(режимный момент)<br>1.О.о «Познавательное развитие»<br>**Ознакомление с окружающим миром**<br>2. О.о. «Художественно - эстетическое развитие»<br>**Музыка** | 8.40-9.00<br>9.00-9.20<br>9.30 – 9.50 | **Чәршәмбе**<br>**Рус теле**<br>(режим вакытында)<br>1. Б.Ө. “ Танып-белү үсеше”<br>**Әйләнә-тирә белән таныштыру**<br>2.Б.Ө. “Сәнгати – эстетик үсеш” **Музыка** |
| **Четверг**<br>1.О.о. Художественно - эстетическое развитие»<br>**Рисование**<br>2. О.о. «Физическое развитие»<br>**Физкультура** | 9.00-9.20<br>09.45-10.05 | **Пәнҗешәмбе**<br>1.Б.Ө. “Сәнгати – эстетик үсеш” **Рәсем**<br>2.Б.Ө. “Физик үсеш”<br>**Физкультура** |

| | | |
|---|---|---|
| **Кружок "Юный эколог"** (режимный момент)<br>II подгруппа | 15.35-15.55 | **"Яшь эколог" түгәрәге**<br>(режим вакытында)<br>II подгруппа |
| **Пятница**<br>**Кружок по логопедии**<br>(режимный момент)<br>1.О.о. «Художественно - эстетическое развитие»<br>**Лепка/аппликация**<br>2. О.о. «Физическое развитие»<br>**Физкультура** | 8.40 - 9.00<br><br>9.00-9.20<br><br>9.45-10.05 | **Җомга**<br>**Логопед буенча кружок**<br>(режим вакытында)<br>1 Б.Ө. "Сәнгати – эстетик үсеш"<br>**Әвәләү/ кисеп - ябыштыру**<br>2.Б.Ө. "Физик үсеш"<br>**Физкультура** |

## 3.3. ХӘРӘКӘТЛЕ РЕЖИМҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ САКЛАУ

| **Шөгыль төре** | **Көндәлек режимда үткәрелгән вакыты** | **Дәвамлылыгы** |
|---|---|---|
| Иртәнге гимнастика | Көн саен | 10 мин |
| Хәрәкәтле разминка | Көн саен шөгыльләр арасында 10 минутлык ялларда | 5-6 мин |
| Физкультминуткалар | Көн саен шөгыльләрдә, кирәге чыккан саен | 3-5 мин |
| Хәрәкәтле уеннар һәм спорт күнегүләре | Көн саен | 25-30 мин |
| Хәрәкәтләр үсешендә индивидуаль эш | Көн саен | 12-15 мин |
| Көндезге йокыдан соң гимнастика | Көн саен урыннарда | 6-10 мин |
| Бармак гимнастикасы | Көн саен | 10-15 мин |
| Күзләр өчен гимнастика | Көн саен буш вакытта | 3-5 мин |
| Артикуляцион гимнастика | Атнага ике тапкыр көннең беренче һәм икенче яртысында | 5-15 мин |
| Сулыш гимнастикасы | Физкультура сәламәтләндерү эшнең төрле формаларында | 2-4 мин |
| Авызны чайкату | Көн саен һәрбер ашаганнан соң | 3-5 мин |
| Физкультура дәресләре | Атнага ике тапкыр | 20 мин |
| Саф һавада физкультура | Атнага бер тапкыр | 20 мин |

| | | |
|---|---|---|
| Мөстәкыйль хәрәкәтле активлылык | Көн саен тәрбияче карамагы астында саф һавада һәм бүлмәдә, дәвамлылыгы балаларның индивидуаль үзенчәлекләреннән чыгып билгеләнә | |

## 4. КУНЕЛ АЧУ ЧАРАЛАРЫ ПЛАНЫ

Күңел ачу чаралары, бәйрәмнәр - һәр балага төркем бүлмәсендә, урамда ирекле уеннар уйнарга, парк, шәһәр урамы буйлап сәяхәт кылырга, актив һәм пассив ял итәргә мөмкинлек, эмоциональ тынычлык бирә, баланың үзенә шөгыль таба белү сәләтен формалаштыра.

| **Д<br>Е<br>К<br>А<br>Б<br>Р<br>Ь** | **“Кыш килде ”.** | **1 атна 5-9 декабрь**<br><br>**Тема:** “Салкын кыш”.<br>**Максат**:Балаларны кыш, табигатьтәге кышкы үзгәрешләр турында күзаллауларын баету.<br>**Бурычлар**:<br>1.Кыш турында балаларның белемнәрен киңәйтү.<br>2. Шигырь, хикәяләр уку, табышмаклар чишү һәм күзәтүләр аша балаларда кыш һәм кышкы табигатькә | Нәфасәти-эстетик үсеш (әвәләү) №4<br><br>Танып белү үсеше (математика) №3 | **“Озын тун кигән кыз”** Эшләнмәнең өлешләрен тоташтырып һәм сылап җыярга өйрәтү.Эшләнмәгә детальләр өстәү күнекмәсен ныгыту. Тирәлекне тоемлап,фикер йөртүне үстерү.<br><br>**Уен – ситуация:”Курчаклар кәрләләр янына кунакка барырга җыена”.**<br>• 5 кә кадәр санарга өйрәтүне дәвам итү.5 санының тәртип мәгүнәсе белән таныштыру. “Ничә?” “Сан буенча ничәнче?”сорауларына җавап бирә белүләрен үстерү.<br>• Предметларны ике күрсәткечена | **Йомгаклау чарасы:** Уен мәйданчыкларын кышка бизәү.<br>Әңгәмә: “Кыш килде”, “Кышкы киемнәр”, “Кышкы табигать”, “Буран”<br>Дид.уен: “Ел фасыллары?”, “Курчакны киендер”,<br>“Кышкы киемнәр”,“Кыш нинди була?”<br>Хәр.уен: “Кем җитез?”, “Курыкмыйм”,”Куяннар” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | соклану хисләре һәм мәхәббәт тәрбияләү.<br>3.Ел фасылы кышның төп үзенчәлекләрен аңлату. Кышкы һава торышын күзәтергә өйрәтү. | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле) **(УМК)** №1<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем) №4<br><br><br><br><br><br><br><br><br>Танып белү үсеше (танып белү) №5 | карап (озынлыгы , киңлеге) чагыштыра белергә, чагыштыру нәтиҗәләрен түбәндәгечә билгеләргә өйрәтүб: кызыл тасма яшеленә караганда озынырак һәм киңрәк, ә яшел тасма кызылына караганда кыскарак һәм тарырак)<br>• Пространство юнәлешен билгели белүләрен камилләштерү: өстә, аста, уңда сулда, алда , артта)<br><br>**“Ап-ак тунлы кыш”**<br>Балаларның кыш турындагы белемнәрен киңәйтү; танып-белү һәм эзләнүгә омтылыш формалаштыру; “аста”, “өстә”, “төбендә” һәм эшчәнлектә кулланган башка фразалар, чагыштыру сыйфатлары хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру; “у” авазын ныгыту; балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, балаларда кызыксыну, бердәм эшләү хисләре тәрбияләү.<br><br>**Кечкенә чыршы**<br>Мөхим өлешләрен генә билгеләп авыр булмаган сюжет ясарга өйрәтү.Аска таба ботакларын зурайта төшеп чыршы ясар-га өйрәтү.Краска белән эшләү кунекмә-ләрен ныгытуны дәвам итү.Образлы күзаллауларын үстерү,матур рәсем ясарга теләк тудыру.<br>Яңа ел бәйрәмен көтү шатлыгы уяту.<br><br>**Кыш килде**<br>Балаларда табигатькә сак караш,соклану хисе тәрбияләү,матурлыкны күрә белергә | **УМК,** “Хәйләкәр төлке”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Морозко”( рус хал.әкияте), “Кыш”(җыр тыңлау Ф.Җәләлетдинова көе,Р.Вәлиева суз)<br>С.рольле уен: «Зоопарк», “Мәктәп”, “Шифаханә”, “Чәчтараш”<br>Матур әдәбият: **УМК** Хәйдәр“Керпе туны”, “Кыш” Ә.Кари, “Шуабыз”Н.Мәдьяров, “Буран” Г.Толымбай |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | өйрәтү.Сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру.Кыш билгеләре белән таныштыруны дәвам итү,сезонлы үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү. | |
| | | **2 атна 12-16 декабрь**<br>**Тема:**”Кошлар һәм хайван-нарның кышкы тормышы”.<br>**Максат**:Балаларның кыш-лаучы кошлар һәм кыргый җәнлекләр турында белем-нәрен баету.<br>**Бурычлар:**<br>1.Балаларның кыргый хай-ваннар һәм кышлаучы кош-лар турында күзаллау-ларын арттыру.<br>2.Өлкәннәр ярдәмендә җимлек куярга өйрәтү.<br>3.Балаларда кошларга ка-рата сакчыл караш, кайгыр-тучанлык сыйфатлары, кыргый хайваннарга карата кызыксынучанлык сый-фатлары тәрбияләү. | Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Нәфасәти- эстетик үсеш (кисеп-ябыштыу)<br>№4<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>**(УМК)**<br>№1 | **Акылбашларның очрашу уены.**<br>• 5 кә кадәр санау күнекмәләрен ныгыту, санауга нигезләнеп предметлар төркеменең тигезлеген, тигезсезлегенбилгели белүләрен формалаштыру.<br>• Предметларны ике күрсәткеченә(озынлыгы, киңлеге) карап чагыштыра, нәтиҗәләрен тиешенчә билгели белергә өйрәтүне дәвам итү (озын, киң юл, кыска тар юл)<br>• Таныш геометрик фигураларны таный һәм атый белүдә күнектерү.<br><br>**“Саесканга муенса”**<br>Турыпочмаклык һәм квадрат почмакларын түгәрәкләргә,төрле формадагы мәрҗән бөртекләрен чиратлаштырырга өйрәтү.Түгәрәк һәм овал турындагы белемнәрне ныгыту, урнаштыру һәм ябыштыру күнекмәләрен үстерү.<br><br>**”Кыргый хайваннар”**<br>Кыргый җәнлекләр турында күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү. Сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү. Кабул итүләрен үстерү.<br>Кыргый хайваннарга карата кызыксыну уяту. | **Йомгаклау чарасы:**<br>Рәсем күргәзмәсе "Кошлар һәм хайваннар кыш көне"<br>Әңгәмә: “Кыш көне кошлар тормышы”, “Җимлек ни өчен кирәк?”, “Хайваннар кышын”, “Төлке кышын ни ашый?”<br>Дид.уен: “Хәрәкәтен әйт”, “Дәвам ит”, “Җимлеккә кемнәр килгән?”,“Үз урынына куй”<br>Хәр.уен: “Поезд”, “Елга аша күпердән”,”Кошлар оча”**УМК,** “Миңа таба йөгерегез”**УМК**<br>**ЭМТЧ**:<br>“Саескан”(Г.Гыйләҗетдинова муз,Х.Гарданов сүз.), “Энә белән җеп”(башкорт хал.уены)<br>С.рольле уен: «Эш кораллары”, “Юлда йөрибез”, “Машина ремонтлыйбыз”, “Без урамга чыгабыз”<br>Матур әдәбият: **УМК** Ә.Кари“Кошлар туйдырам”, “Карт белән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4<br><br><br><br><br><br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>**(УМК)**<br>№1 | **“Җиргә ак кардан юрган ябылган”**<br>Балаларны алдан уйлап эшләргә,рәсемаша,үу тойгыларыңны җиткерә белергә өйрәтү.Рәсем ясауның таныш алымнарын куллана белүне үстерү.Туган як табигате белән соклану хисләре тәрбияләү.<br><br>**“Җәнлекләр кышка әзерләнә”**<br>Балаларны җәнлекләрнең кышкы яшәү рәвеше белəнтаныштыру.Грамматик яктан дөрес сөйләмне үстерү.Тере табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү. | төлке”татар хал.әкияте,<br>“Кыш”Җ.Тәрҗеманов<br>“Оекбаш” Р.Корбан |
| | | **3 атна 19-23 декабрь**<br><br>**Тема:** “Кышкы куркыныч-сызлыклар”.<br>**Максат:** Кышкы чордагы куркынычсызлык кагый-дәләре күнекмәләрен ка-милләштерү.<br>**Бурычлар:**<br>1.Кыш көне юлда үз-үзең-не тоту кагыйдәләре белән таныштыру.<br>2.Юл билгеләренә һәм све-тофорга карап ориентлашу күнекмәләрен формалаш-тыру, игътибарлылыкны, хәрәкәт координациясен үстерү.<br>3.Юлларда үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү. | Нәфасәти- эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br><br><br><br><br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3 | **Чыпчык**<br>Балаларны кош әвәләргә,аның төп өлешләренең формасын һәм пропорцияләрен дөрес итеп җиткерә белергә өйрәтү.<br>Әвәләп ясау алымнарын ныгыту,сынны тулыландыру.<br><br>**Уен – ситуация “Серле капчык”**<br>• 5 эчендә тәртип саны турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү, “Ничә?”, “Ничәнче санда?” “Нинди урында?” сорауларына җавап бирә белүләрен ныгыту.<br>• Цилиндр белән таныштыру, шар һәм цилиндрны аера белергә өйрәтү.<br>• Предметларны төсенә, формасына, зурлыгына карап чагыштыра белүләрен үстерү. | **Йомгаклау чарасы:** квест уен “Кышкы куркынычсызлыклар”.<br>Әңгәмә: “Кышкы курку-нычсызлык”, “Бозлавык”, “Кар көртләре”, “Куркыныч урыннар”<br>Дид.уен: “Өч квадрат”, “Кемгә нинди форма”, “Ярый-ярамый”,“Нәрсә югалды”<br>Хәр.уен: “Чы”, “Бөжралар”,”Кошлар оча”**УМК,** “Тупны сетка аша ыргыт”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Давыл”( башкорт хал.уены), “Балыкчы аю”(татар хал.әкияте)<br>С.рольле уен: “Китапханәдә”, “Төзүчеләр”, “Кибетче”, “Милиционер”<br>Матур әдәбият: **УМК** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сөйләм үсеше (сөйләм теле) **(УМК)**<br><br><br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем) №4<br><br><br><br>Танып белү үсеше (танып белү) **(УМК)** | **Үз үзеңне сакла**<br>Юл кагыйдәләрен саклауны өйрәтүне дәвам итү.Юлда очрый торган куркыныч ситуацияләр турында белемнәрен ныгыту. Юл кагыйдәләрен сакларга теләк уяту; җаваплылык хисләре тәрбияләү**.**<br><br>**Чакыру билеты**<br>Балаларны мөстәкыйль рәсем эчтәлегенә төшенергә һәм уйлаганнарын сүрәтләргә өйрәтү. Буяу белән рәсем ясау алымнарын ныгыту.Фантазияләрен,иҗадый фикерләүләрен, якыннарын шатландыру теләкләрен көчәйтү.<br><br>**Кышкы юллар**<br>Кышкы чордагы юл йөрү куркынычсыз-лык кагыйдәләре күнекмәләрен камил-ләштерү. | А.Алиш“Бикбатыр һәм Биккуркак”, “Койрык” Ә.Гаффар, “Комсыз эт” К.Насыйри, “Тиен” Ә.Кари |
| | | **4 атна 26-30 декабрь**<br>**Тема:** “Хуш киләсең Яңа ел!”.<br>**Максат**:Балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту.<br>Бурычлар:<br>1.Балаларга Яңа ел уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыру.<br>2.Яңа ел бәйрәме уңаеннан балаларның тирә-юнь турындагы күзаллауларын киңәйтү.<br>3.Яңа елга карата кызыксыну тәрбияләү. | Нәфасәти-эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру) №4<br><br><br>Танып белү үсеше (математика) №3 | **Бәйрәм открыткасы**<br>Төсләр сайлап,композиция уйлап, катлаулы булмаган сюжет төзү.<br>Кисеп-ябыштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>Яңа елны бәйрәм иткәндә шатлык халәтен тоярга өйрәтү.<br><br>**Уен – ситуация : “Картиналар төзү”**<br>• 5 эчендәге предметларны санау һәм санап аерып алуда күнектерү.<br>• Цилиндртурында күзаллауларын ачыклауны дәвам итү. Шар, куб, цилиндрны аера белүләрен ныгыту.<br>• Тәүлек өлешләренең тәртибе турында күзаллаулрын ныгыту | **Йомгаклау чарасы:** “Яңа ел чыршысының иң матур йолдызы”на күргәзмә.<br>Әңгәмә: “Хуш киләсең,Яңа ел!”, “Бәйрәм иртәсе”, “Бизәлгән чыршы”, “Кыш бабай бүләкләре”<br>Дид.уен: “Чыршы уенчыклары”, “Озын-кыска”,<br>“Серле чәчәк”,“Бу кайсы әкияттән?”<br>Хәр.уен: “Тота бел”, “Бөҗралар”,”Тизрәк урыныңа бар”**УМК,** “Кар йомарламнары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Сөйләм үсеше (сөйләм теле) **(УМК)** №1<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем) №4<br><br>Танып белү үсеше (танып белү) **УМК** №1 | **Чыршыкай-купшыкай**<br>Яңа ел бәйрәме, чыршы турында күзал-лаулар формалаштыруны дәвам итү; сөйләмнең грамматик төзелешен камил-ләштерү, хикәя төзү осталыгын, кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, бармак-лар моторикасын үстерү; күтәренке кәеф атмосферасы тудыру.<br><br>**Кыш бабай**<br>Рәсем аша бәйрәм тойгыларын җиткерә белергә,Кыш бабайны сүрәтләргә өйрәтү.Сүрәтне кәгазь битенә сыйдыру,уртага урнаштыруны ныгыту.Рәсемне тулыландырганда иҗадый эшләүне үстерү.<br><br>**Яңа ел килә...**<br>Балаларда Яңа ел бәйрәме турында бе-лемнәрен формалаштыруны дәвам итү, сенсор билгеләре буенча бертөрле пред-метларны төркемгә берләштерү осталы-гын ныгыту; балаларның чыршы уен-чыкларының төсен, формасын, зурлы-гын, кулланылышын билгеләү, диалогик сөйләмен, сорауларга җөмлә белән җа-вап бирү осталыгын, хисси тәҗрибәсен, кабул итүләрен үстерү;балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре уяту. | ыргытабыз"**УМК ЭМТЧ**: "Чыршы янында"( түгәрәк уены И.Шәмсетдинов көе), "Һай,Кыш бабай"( түгәрәк уены И.Шәмсетдинов көе) С.рольле уен: «Кыш бабай", "Машина ремонтлыйбыз", "Яшелчә кибетендә", "Кунакка барабыз"<br>Матур әдәбият: **УМК** М.Файзуллина"Кыш бабай", "Чыршы әйләнәсендә" Р.Миңнуллин, "Кыш бабай килгән"Р.Корбан "Чыршы"Ә.Ерикәй |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Я<br>Н<br>В<br>А<br>Р<br>Ь** | **“Эш яратудан осталык туа”** | **2 атна 9-13 январь**<br>**Тема: “ Һөнәрләр”**<br>**Максат:**балаларны олылар хезмәте (һөнәрләр)белән таныштыру .<br><br>**Бурычлар:** 1.Һөнәрләр турында кызыксынучанлыкларын киңәйтү.<br><br>2.Логик фикерләү сәләтләрен үстерү.<br>3.Төрле һөнәр ияләренең хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>. | Нәфасәти-эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>Әдәбият №4 | **Төлке**<br>Балаларны предмет өлешләрен әвәләп ясарга өйрәтү,детальләрне сузып,тоташтырып һәм сылап, өлешләрнең пропорцияләрен күрсәтә белү. Тиешле әвәләү алымнарын сайлау күнекмәсен ныгыту,эшләнмәне ахырына җиткерү.<br>Хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү.<br><br>**Уен: “Аюның йокысы”**<br>• Үрнәк һәм бирелгән сан буенча 5 эчендә предметларны санап аерып алуда һәм санауда күнектерү<br>• Якын-ерак сүзләренең мәгүнәсе белән таныштыру.<br>• Бер бөтен рәсемне кисәкләрен берләштереп төзи белүләрен үстерү.<br><br>**Һөнәрләр**<br>Һөнәрләр исеме белән таныштыру,<br><br>һәр пофессиянең кирәкле булуын аңлату.<br><br>Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү.Төрле һәнәр ияләренең хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>**Тәрәзәдәге кышкы бизәкләр**<br>Рәсемдә чынбарлык күренешләрен гәүдәләндерергә өйрәтү.Пумаланы басып бөтен биткә бизәк төшерү күнекмәсен ныгыту.Рәсемне алдан уйлап куярга гадәтләндерү.Туган як табигате белән соклану хисләре тәрбияләү. | **Йомгаклау чарасы:**<br>Һөнәр ияләре белән очрашу.<br>Әңгәмә: “Минем әти-әнием кем булып эшли”, “Мин кем булырга телим”, “Һөнәрләр”,<br>Картиналар карау.УМК<br>Дид.уен: “Кемгә нәрсә кирәк?”,“Өч квадрат”, “Кемгә нинди форма”,<br>Хәр.уен: “Божралар”, ”Кошлар оча”**УМК, ЭМТЧ**: “Давыл”( башкорт хал.уены), “Балыкчы аю”(татар хал.әкияте)<br>С.рольле уен: “Шифаханәдә”, “Төзүчеләр”, “Кибетче”, “Милиционер”<br>Матур әдәбият:<br>ВУраксина “Кем булып эшли ?” Х.Халиков “Без төзүчеләр”,<br>Э.Шарифуллина “Шофер буласым килә”,Ә.Карый “Минем әни тегүче”, Э,Моэминова “Фокусы”(УМК 1.2),<br>**Бармак уены:**<br>“Һөнәрләр” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | Балаларның һөнәрләр турында танып белү сәләтен арттыру.Хезмәт коралларын класификцияләү осталыгын игътибарын, олылар хезмәтенә карата кызыксынуын үстерү. Төрле һөнәр ияләренә хөрмәт тәрбияләү. | |
| | | **3 атна 16-20 январь**<br>**Тема:** “Халык җәүһәрләре”<br>**Максат**:Балаларны татар халкының көнкүреш һәм гореф – гадәтләре, йолалары, уеннары белән тирәнтен таныштыру, балаларның зәвыгын үстерү,халкыбызның рухи байлыгына ихтирам, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү.<br>**Бурычлар:** туган як тарихы, гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте турында белемнәрне тирәнәйтү. | Нәфасәти- эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>**(УМК)**<br>№2<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>**ФГОС** №6<br><br>Танып белү үсеше | **Кар бөртекләре**<br>Балаларны кайчы белән 2-3 хәрәкәт ясап, киң кәгазь тасмалар кисеп алырга өйрәтү. Кар бөртекләре кисү күнекмәсен булдыру. Уен аша аралашуга ирешү.<br>**Уен – ситуация: “Матрешкалар белән уйныйбыз”**<br>Авазларны ишетеп 5 эчендә санап санын билгеләүдә күнектерү.Якын-ерак сүзләренең мәгүнәсен белүләрен ачыклау.Өч предметның зурлыгын чагыштыра, үсү һәм кимү тәртибендә тезә, чагыштыру нәтиҗәләрен түбәндәгечә билгеләргә өйрәтү: озын, кыскарак, бик кыска, кыска, озынырак, бик озын.<br>**“Без әкият яратабыз”**<br>Халык авыз иҗаты әкиятләр белән таныштыруны дәвам итү.Кабул итү, игътибарын, тикшерү (эксперимент үткәрү), сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү, диалоглы сөйләмне камилләштерү.Балаларда чисталык,пөхтәлек, үзара ярдәм, яхшылыкка омтылу теләге тәрбияләү.<br>**Үз теләгең буенча рәсем ясау**<br>Б-ны рәсемнең эчтәлеген уйларга һәм уйлаганнарын ахыргача җиткерергә өйрәтү. Мөстәкыйльлек һәм иҗадыйлыкны үстерү.<br>**“Халкыбызның мирасы белән** | **Йомгаклау чарасы:**<br>Милли киемнәр бизәү.<br>Әңгәмә. “Минем халкым”, “Милли киемнәр”<br>Матур әдәбият: Р.Вәлиева “Кәләпүшем,кәләпүш”, В.Хәйруллина “Түбәтәй”, Л.Әмирханова “Чигүле читекләрем”.<br>Дидактик уен: “җөмләне әйтеп бетер”, “Курчакның киемен тасвирла”, “Түбәтәйне бизә”<br>Хәрәкәтле уен: “Әбәк-күбәк” (башкорт халык уены), “Тилгән” (рус халык уены)<br>Җырлы-уен “Кәрия-Зәкәрия”, “Түбәтәй” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | (танып белү) №1.3, 144 бит | **кызыксыну”**<br>Татар халкының декоратив кулланма сәнгать үрнәкләре белән таныштыру.Әби-бабаларыбыз иҗат иткән әйберләргә хөрмәт тәрбияләү. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **4 атна 23-27 январь**<br>**Тема:** “Юл тәртип ярата” (ПДД атналыгы)<br>**Максат:**Балаларда тормыш иминлеген саклау турында күзаллау булдыру. Юл шартларында үзеңнне хәвефсез тоту ни-гезләре буенча белемнәр һәм күнекмәләрне камил-ләштерү.<br>**Бурычлар:**<br>1)балаларда урамда,җәмәгать транспортында, торак зонасында уз-үзеңне тоту культурасы тәрбияләү.<br>2) Юлларда күзәтүчәнлекне,игътибарлы лыкны үстерү.<br>3)Юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү. | Нәфасәти- эстетик үсеш (әвәләү)<br>**ФГОС**<br>№6<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>**(УМК)** №1<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем) №6<br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>**(УМК)** №5 | **“Уйлап әвәләү”**<br>Иҗадыйлык һәм мөстәкыйльекне үстерүне дәвам итү.Әвәләүнең төрле алымнарын кулланууны камилләштерү.Күзаллауны үстерү.<br><br>**Уен – ситуация: “Юллар төзибез”**<br>Авазларны ишетеп 5 эчендә санап санын билгеләүдә күнектерү.Өч предметның зур-лыгын чагыштыра, үсү һәм кимү тәртибен-дә тезә, чагыштыру нәтиҗәләрен түбәндә-гечә билгеләргә өйрәтүне дәвам итү: озын, кыскарак, бик кыска, кыска, озынырак, бик озын.Таныш геометрик фигураларны та-ный һәм атый белүдә күнектерү: квадрат, өчпочмак, түгәрәк, турыпочмак.<br><br>**“Синең куркынычсызлыгың-синең кулларда”**<br>Балаларны куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру:тротуар, “җәяүлеләр юлы”,машина юлы,куркынычсызлык каешы кебек сүзләр хисабына сүзлек запасын баету.<br><br>**“Юлны флаглар белән бизибез”**<br>Балаларны турыпочмаклык формасы ясауда күнектеру.Рәсемне тигез буяуга ирешү.Ритмны, эстетик тоемлауны үстерү.<br>**“Транспорт төрләре”**<br>Велосипедта хәвефсез йөрү кагыйдәләрен өйрәтү.Бирелгән мәгълүматны тыңлый белү һәм үзләштерүне формалаштыру. | **Йомгаклау чарасы:** Кул эшләренә күргәзмә.<br>Әңгәмә: “Светофор”, “Юл транспорты”, “Юл йөрү кагыйдәләре”, “Юл билгеләре”<br>Дид.уен: “Бу кайсы билге”, “Кызыклы шакмак”,“Домино”, “Транспорт төрләре”<br>Хәр.уен: “Төз ат”, ”Йөгерегез” “Куян нар”,”Поезд”**УМК,** “Мин сикерәм, син кул чәбәклә”**УМК ЭМТЧ**: “Туп һәм чокыр”(удмурт хал.уены), “Ата каз”(тат.хал.әкияте)<br>С.рольле уен: «Без юлда йорибез”, “Пассажирлар”, “По -лиция”, “Шоферлар”<br>Матур әдәбият: **УМК** З.Туфайлова “Шофер булам”, “Светофор тәмле тамак” Л.Лерон, “Светофор”Р.Бәшәр“Свет офорның өч күзе”<br>Бармак уены: “Яшелчәләр җыябыз”. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Ф<br>Е<br>В<br>Р<br>А<br>Л<br>Ь** | **“Батыр булып тумыйлар, батыр булып үсәләр”.** | **1 атна 30 январь-<br>3 февраль**<br><br>**Тема:** “Дуслык-бөек көч”<br>**Максат:** Әкиятләр аша яхшылыкны яманлыктан, дөресне ялганнан, гаделлекне икейөзлектән аерырга өйрәтү.<br>**Бурычлар:**<br>1.Балаларда матур әдәбият белән кызыксыну һәм аны ярату хисләре тәрбияләү.<br>2.Үз фикерен ана телендә эзлекле ,җыйнак,төгәл һәм матур итеп әйтеп бирә белү,иҗади фикерләү сәләтен үстерү.<br>3.Сорауларга тулы ,төгәл җавап бирергә, геройларның кылган эшләренә,әхлакый сыйфатларына бәя бирә белергә,әкиятләрне һәм мәзәкләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү. | Нәфасәти- эстетик үсеш (кисеп-ябыштыу)<br>**ФГОС**<br>№4<br><br><br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№2<br><br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4<br><br><br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | **Тәлинкә бизибез**<br>Түгәрәкне өйләнә буенча һәм үзәген бизәргә өйрәтү.Квадратлардан түгәрәкләр кисү,әзер формаларны урнаштыру һәм ябыштыру күнекмәләрен ныгыту.Бизәкне чиратлаштырырга өйрәтү<br><br>• 5 эчендә предметларны капшап карап санауда күнектерүне дәвам итү<br>• Кичә, бүген , иртәгә сүзләренең мәгнәсе турындагы күзаллауларын ныгыту.<br>• Өч предметны киңлеге буенча чагыштырырга, үсү һәм кимү тәртибе буенча тезергә һәм чагыштыру нштиҗәләрен киң, тарырак, бик тар, тар, киңерәк, бик киң сүзләре белән билгеләргә өйрәтү.<br><br>**“Туган телемдә сөйләшәм”**<br>Балаларда туган телебезне ярату,белү,туган телдә сөйләшү теләге тәрбияләү.<br><br>**“Керпе сүрәте”**<br>Пумала белән һәм бармак очлары белән баскалап рәсем ясау алымын өйрәтү. Сүрәтне битнең уртасынаурнаштыру,кара һәм көрән төсләрне әйтә белүне ныгыту.<br><br>**“Без уйныйбыз”**<br>Сөйләмдә гомумиләштерүче сүзләрне кулланырга өйрәтү. Актерлык осталыгын үстерү. Сәхнә культурасы тәрбияләү. | **Йомгаклау чарасы:** әкиятләр сәхнәләштерү ( балалар өчен ).<br>Әңгәмә: “Кем ул актер”, “Без артистлар”, “Театр”, “Сәхнә нәрсә ярата?”<br>Дид.уен: “Лото”, “Тылсымлы капчык”, “Кызыклы сәгать?”,“Домино”<br>Хәр.уен: “Тота бел”, “Яңгыр”,”Елга аша күпердән”, “Куяннар”<br>**ЭМТЧ**: “Исемен ата”(башкорт хал.уены), “Матур уен”(татар хал.уены)<br>С.рольле уен: «Цирк”, “Курчак театрында”, “Бармак театры”, “Өстәл театры”<br>Матур әдәбият: К.Ушинский“Хайваннар бәхәсе”,”Куян күчтәнәче, яки тешсез малай”<br>З.Хөснияр, “Кем бутаган?”, Р.Харис “Юмартлар”,” **УМК**<br>Бармак уены: “Ялкау бармак” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **2 атна 6 -10 февраль**<br><br>**Тема:** “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел” (рус теле атналыгы)<br>**Максат:**Татар һәм рус телләренә карата ихтирам тәрбияләү.<br>**Бурычлар:**<br>1.Балаларда кешеләрнең милләтләре буенча аерылулары турында күзаллау тудыру.<br><br>2.Ике телдә балаларның сөйләм телен үстерү.<br><br>3.Милләтләргә карата хөрмәт тәрбияләү. | Нәфасәти-эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (танып белү) №5 | **Үз теләгең буенча әвәлә**<br>Милли ризыклар белән таныштырып, кеше-ләрнең милләтләре буенча аерылулары ту-рында күзаллау тудыру.Сүрәт әвәләп яса-ганда,өлешләрне ялгау күнекмәләрен ныгыту.Уен уйлап чыгару сәләтен үстерү.<br><br>**Уен–ситуация: “Простоквашинодан хат”**<br>5 эчендә әйтелгән сан буенча хәрәкәтләр эшләп күрсәтергә өйрәтү.Таныш геометрик фигураларны аера һәм атый белүдә күнектерү (түгәрәк, квадрат, өчпочмак, турыпочмак.).Тәүлек өлешләре турында күзаллауларын камилләштерү : иртә, кич, көн, төн.<br><br>**“Язны каршылыйбыз”.Эндәш өйрәнү.**<br>Рус телендә масленица темасына карата эндәш өйрәнү.Ике телдә балаларның сөйләм телен үстерү.Милләтләргә карата хөрмәт тәрбияләү.Төрле милләт уеннарын, җырларын тыңлау.<br><br>**“Кызык уенчыклар”(Дымкова бизәкләренә охшатып ясау)**<br>Рус халык уенчыклары белән таныштыруны дәвам итү.Гәүдә өлешләренә туры китереп, хайван сүрәтләренә Дымково бизәкләре төшерергә өйрәтү.Халык уенчыгы белән соклану хисләрен тәрбияләүне дәвам итү.<br>**Туган тел көне**<br>Төрле милләт кешеләренә ихтирам тәрбия-ләү.Балаларда фикерләү сәләтен үстерү. | **Йомгаклау чарасы:**<br>“Туган тел көне” күңел ачу чарасы үткәрү.<br>Әңгәмә: “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел”, “Рус халык киемнәре”, “Милли уеннар”, “Май чабу<br>бәйрәме”<br>Дид.уен: “Хатаны тап”, “Серле чәчәк”,<br>“Парын тап”,“Нинди төстә”<br>Хәр.уен: “Очкычлар”, “Тычканнар”,”Шалтыравык”**УМК,** “Мин сикерәм,син кул чәбәклә”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Балыкчы аю”(тат. хал.экияте), “Бобовое зернышко”(рус хал.экияте)<br>С.рольле уен: «Без балалар бакчасында”, “Өй-өй”, “Кунак чакырдык”, “Без урамга чыгабыз”<br>Матур әдәбият: **УМК** Р.Вәлиева“Кыңгырау чәчәк”,ятлау Ш.Маннур “Татарча да яхшы бел, урысча да яхшы бел”<br>Ф.Тарханова“Зарядкага бас!” ,“Торна белән төлке”( тат.хал.экият),”Төлке,әтәч |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Төрле миллəт уеннарын,җырларын тыңлау. | һəм песи”(Рус хал.əкияте) Бармак уены:“Бармакларны киендерəбез”. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **3 атна 13-17 февраль**<br>**Тема: Муса Җəлил- герой шагыйрь”**<br>**Максат:**Балаларны Муса Җəлил турында белемнəрен киңəйтү.<br>Бурычлар:<br>1.Муса Җəлил иҗаты белəн таныштыруны дəвам итү.<br>2.Аның иҗатына соклану хислəре тəрбиялəү.<br>3.Балаларда М.Җəлил əсəрлəрен өйрəнүгə кызыксыну уяту. | Нəфасəти-эстетик үсеш (əвəлəү)<br>№4<br><br><br><br><br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Сөйлəм үсеше (сөйлəм теле)<br><br><br><br><br><br>Нəфасəти-эстетик үсеш (рəсем)<br>№4 | **“Түтəлемдə гөллəр чəчəк атты”**<br>Таҗ яфракларын чəчəк үзəге тирəсендə бер рəт итеп тезеп түгəрəк чəчəк сүрəте төзергə өйрəтү.<br>Иҗатка омтылыш тəрбиялəү.Үз эшлəренə соклану хислəре уяту.<br><br>**Уен – ситуация: “Зарядка ясыйбыз”**<br>• 5эчендə хəрəкəтне санарга өйрəтү;<br>• тирə-юньдə ориетлаша белергə һəм əйлəнə-тирəдəге юнəлешне үзенə карата билгелəргə күнектерү: өстə-аста,уңда-сулда,алда-артта,<br>• 4-5 предметны киңлеге буенча чагыштырырга үсү һəм кимү тəртибе буенча тезергə һəм чагыштыру нштиҗəлəрен киң, тарырак, бик тар, тар, киңрəк, бик киң сүзлəре белəн билгелəргə өйрəтү.<br><br>**М.Җəлилнең “Сəгать” шигырен ятлау**<br>М.Җəлил иҗаты белəн таныштыру.Хəтерне,суз байлыгын,сөйлəм телен үстерү.М.Җəлил иҗатына хөрмəт,мəхəббəт тəрбиялəү. сəнгатьле итеп таныш шигырьлəрен сөйлəүлəренə ирешү**.**<br><br>**Матур күбəлəклəр**<br>Күбəлəк силуэтын ,аның элементларын сайлап,урнашу симметриясен саклап | **Йомгаклау чарасы:** шигырь бəйрəме “Муса Җəлилнең батырлыгы, исеме үлемсез”.<br>Əңгəмə: “Кем ул Муса Җəлил?”, “М.Җəлил шигырьлəре”, “Батырлык”,<br>Дид.уен: “Кем чакырганын бел”, “Дəвам ит”,<br>“Кыршау белəн уен”,“Тупны тот та,төсен əйт”<br>Хəр.уен: “Очкычлар”, “Тычканнар”,”Шалтыравык”**УМК,** “Мин сикерəм,син кул чəбəклə”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Əбəк-күбəк”(башкорт хал.уены), “Зур туп”(рус хал.əкияте)<br>С.рольле уен: «Китапханə», “Зоопарк”, “Кунак чакырдык”, “Без урамга чыгабыз”<br>Матур əдəбият: **УМК** “Сəгать”, “Əтəч” , “Чишмə”,“Кəккүк” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | бизәргә өйрәтү.Пумала очы белән кагылып –кагылып ясау техникасын ныгыту.Төсләрне җирлек белән яраклаштырырга өйрәтү.<br><br>**Чәчәкләр дөньясы**<br>Чәчәкләргә соклану хисе тәрбияләү. М. Җәлил иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Сөйләгәнне аңлап кабул итәргә күнектерү. | Бармак уены: “Бармакларны киендерәбез”.<br>Өстәл уены: “Пазл” |
| | | **4 атна 20-24 февраль**<br>**Тема:** “Ватанны саклаучылар көне”<br><br>**Максат:**Ватанны саклау-чылар турында белемнәрен киңәйтү.<br>**Бурычлар:**<br>1.Балаларга “Ватанны сак-лаучылар” турында төшен-чә бирү.<br>2.Җирне, күкне, диңгезне саклаучылар турындагы белемнәрне шигырьләр, хикәяләр, табышмаклар чишү аша мөһимлеген аң-лату.<br>3.Балаларда кыю, батыр | Нәфасәти-эстетик үсеш (кисеп ябыштыру)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3 | **Әтигә открытка**<br>Балаларны детальләрдән үзләре күзаллаганча дөрес итеп сүрәт төзергә өйрәтү.<br>Турыпочмаклыклар,түгәрәкләр,өчпочмаклар кисү күнекмәсен кабатлау.<br>Солдат хезмәтенә,армиягә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>**Уен – ситуация: “Степашка уенчыклар җыя”**<br>• 5 эчендә әйтелгән сан буенча хәрәкәтләр эшләп күрсәтә белүдә күнектерү<br>• Күрсәтелгән юнәлеш уенча хәрәкәт итәргә өйрәтү (алга, артка, уңга, сулга) | **Йомгаклау чарасы:**<br>Әтиләрне бәйрәм белән котлау-бүләк тапшыру.<br>Әңгәмә: “Абый да солдат булган,әти дә солдат булган...”, “Мин солдатка барам”, “Безнең армия”, “Хәрби машиналар”<br>“Хәрби машиналар”<br>Дид.уен: “Ягымлы сүзләр”, “Серле чәчәк”, “Кайсы артык?”,“Гаилә әгъзалары”<br>Хәр.уен: “Очкычлар”, “Тычканнар”,”Шалтыравык”**УМК,** “Мин сикерәм,син кул чәбәклә”**УМК** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | солдат булу теләге уяту, этиләре, абыйлары, бабай-лары белән горурлану хисе тәрбияләү | Сөйләм үсеше (сөйләм теле) №1<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем) №6<br><br>Танып белү үсеше (танып белү) №1 | Аерым өлешләрдән предметның бербөтен рәсемен төзи белүдә күнектерү.<br><br>**Хәрби һөнәрләр**<br>Балаларның хәрби һөнәрләр һәм алар-ның төрләре, танк турындагы белем-нәрен формалаштыру; исем, сыйфат кулланып, гади җөмләләр төзергә өй-рәтү: балаларның кызыксынуын, игьти-барын, хәтерен, хәрәкәтен, фикерләвен үстерү; балаларда хәрби һөнәрләргә хөр-мәт тәрбияләү<br><br>**Болытлар аша самолетлар оча**<br>Балаларның рәсемендә болытлар аша самолет очканлыгын рәсемләү, уйлау фикерләү сәләтләрен үстерү,.<br>**Без солдатлар**<br>Балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру; очкычның (самолет), вертолетның өлешләрен, формасын ае-рырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнек-мәләре формалаштыруны дәвам итү; солдат, очучы, диңгезче, очкыч, вертолет, корабль сүзләре хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру; балаларда очу-чы, диңгезче, хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр, малайларда көчле, кыю булу теләге тәрбияләү. | **ЭМТЧ**: “Карт белән төлке”(тат.хал.әкияте), “Шома бас”(тат. хал.көе)<br>С.рольле уен: «Чик сакчылары”, “Без-хәрбиләр”, “Разведчиклар”, “Шоферлар”<br>Матур әдәбият: **УМК** Р.Миңнуллин“Туган илнен улы мин”, К.Булатова“Солдатлар” , А.Алиш“Бикбатыр белән Биккуркак”<br>Бармак уены: “Уенчыклар”.<br>Өстәл уены: “Мозайка” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **М<br>А<br>Р<br>Т** | **“Ямьле яз”** | **1 атна 27 февраль-3 март**<br><br>**Тема:** “Табигатьтә яз”<br>**Максат**:Балаларның хәтерендә язның төп билгеләрен ныгыту.<br>**Бурычлар:**<br>1 Табигатьнең матурлыгын күрә,соклана белергә өйрәтү,әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә игътибаритү.<br>2.Иҗади күзаллауларын үстерү, сүз байлыгын үс-терү.<br>3.Балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | Нәфасәти-эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br><br><br><br><br><br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№1<br><br><br><br><br><br><br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4 | **Кошкаем**<br>Кош образын әвәләп ясарга өйрәтүне дәвам итү,аларның язгы тормышы белән таныштыру<br>Әвәләп ясауның таныш алымнарын куллана белү кунекмәсен ныгыту.<br>Өстәмәләр кертү аша иҗадди күзаллауны үстерү.<br><br>**Уен – ситуация:”Чәй өстәле әзерләү”**<br>• Санау нәтиҗәсе предметның зурлыгына бәйле булмавы турындагы күзаллауларын ныгыту<br>• Өч предметның биеклеген чагыштыра , үсү, кимү тәртибендә тезә һәм чагыштыру нәтиҗәләрен биек, тәбәнәгерәк, иң тәбәнәге, биегерәк, иң биеге сүзләре белән билгеләргә өйрәтү<br><br>**Аюның язгы мажаралары**<br>Балалары исем,сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү.Язның төп билгеләрен ныгыту.<br>Балаларның кызыксынуын,фикерләвен,хәтерен үстерү.<br>Балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү<br><br>**Язын безгә ниләр ошый?**<br>Балаларның яз турындагы хис-тойгыларын рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү.Кәгазь битенә рәсемне уңышлы урнаштыру күнекмәсе булдыру.Төс,форма,күләм чамалауны үстерү. | **Йомгаклау чарасы:**<br>Сыерчык оялары урнаштыру.<br>Әңгәмә: “Яз килде”, “Язгы киемнәр”, “Язгы табигать”, “Яфрак яра ак каен”<br>Дид.уен: “Ел фасыллары?”, “Курчакны киендер”,<br>“Язгы киемнәр”,“Яз нинди була?”<br>Хәр.уен: “Кем җитез?”, “Курыкмыйм”,”Куяннар”<br>**УМК,** “Хәйләкәр төлке”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Буяу сатыш”( башкорт хал.әкияте), “Шаян казлар”(рус хал уены)<br>С.рольле уен: «Зоопарк”, “Мәктәп”, “Шифаханә”, “Чәчтараш”<br>Матур әдәбият: **УМК**<br>С.Маршак“Апрель”, “Яз килщ” Н.Гайсин, “Яз җитә”Ф.Кәрим,<br>“Бу кайсы вакыт?” Г.Тукай<br>Ятлау “Яз” Р.Вәлиева |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | **Урамда яз**<br>1 Табигатьнең матурлыгын күрә,соклана белергә өйрәтү,әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә игътибар итү.<br>2.Иҗади күзаллауларын үстерү, сүз байлыгын үстерү.<br>3.Балаларда табигатькә сакчыл караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | |
| | | **2 атна 6-10 март**<br><br>**Тема:**"Әнием кадерлем".<br>**Максат:**Әниләр бәйрәме турында белемнәрен ки-ңәйтү.<br>Бурычлар:<br>1.Балаларны әниләр бәйрә-ме турындагы мәгълүмат-ларын ныгыту;сәнгатьлелек чараларын куллануда кү-нектерү.<br>2.Әниләр турында тасвир-лау хикәясе сөйләргә һәм фотография кулланып, эз-лекле сөйләүләрен үстерү.<br>3.Әниләргә мәхәббәт һәм ярдәм итү теләге тәрбияләү. | Нәфасәти-эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№1 | **Әниемә бүләк**<br>Балаларны өч таҗ яфрагыннан энҗе чәчәк,чәчәк касәсе,сабак һәм яфрак төзергә өйрәтү.Матур бүләк ясау омтылышы тәрбияләү.Әниләргә хөрмәт,җылы хисләр тәрбияләү.<br><br>**Уен – ситуация:"Дөрес барсаң ящерелгән әйберне табасың"**<br>• Билгеләнгән юнәлеш буенча хәрәкәт итә белүләрен ныгыту.<br>• Санау нәтиҗәсе предметның зурлыгына бәйле булмавын аңлату(5 эчендә)<br>• 5 эчендә предметларны зурлыгына карап чагыштыра, үсү, кимү тәртибендә тезә, чагыштыру нәтиҗәләрен түбәндәгечә билгели белергә өйрәтү (иң зур, кечкенәрәк, тагын да кечкенәрәк, иң кечкенә, зурырак)<br><br>**Әниләр бәйрәме**<br>Балаларны әниләр бәйрәме турындагы мәгълүматларын киңәйтү; әниләр ту-рында | **Йомгаклау чарасы:**<br>Гаилә бәйрәме<br>Әңгәмә: "Мин әнине яратам", "Мин әнигә булышам", "Кызларны без хөрмәтлибез", "8 март бәйрәме"<br>Дид.уен: "Нәрсәдән ясалган?", "Дәвам ит", "Яхшы-начар","Тупны тот та,төсен әйт"<br>Хәр.уен: "Еракка ыргыт", "Божралар","Кошлар оча"**УМК,** "Тупны сетка аша ыргыт"**УМК**<br>**ЭМТЧ**:музыка тыңлау "Әни кирәк"( М.Шәмсетдинова муз), "Миңлебай"(тат хал.җырлы уены)<br>С.рольле уен: «Әниле-кызлы", "Бәйрәм өстәле әзерлибез", "Әни эштән кайтты", "Әни аш пешерә" |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№6<br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>№1 | тасвирлау хикәясе сөйләргә өйрә-тү; балаларның игътибарын, кабул итү-ләрен, хәтерләрен, фотография куланып, эзлекле сөйләүләрен үстерү; әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.<br><br>**Әниемә яулык бизим**<br>Балаларны милли бизәкләр белән та-ныштыру,бизәу алымнарын ойрэту, эсте-тик зәвык, чиста пөхтә итеп буяуларына ирешү.<br><br>**Әнием турында сөйлим**<br>Бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү; әниләр турында тасвирлама төзү осталыгын формалаштыру; кабул итүне, хәтерне, игътибарны, сүзлек байлыгын үстерү, сәнгатьлелек чараларын кулла-нуда күнектерү; әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. | Матур әдәбият: **УМК** Ә.Бикчәнтәева“Минем әнием”, “Әниләр бәйрәме” С.Сөләймanovанова, “Бүләк” Д.Хабибуллина, “Ахмак бүре”әкият |
| | | **3 атна 13-17 март**<br><br>**Тема:** “Татар мәдәнияте атналыгы”<br>**Максат**:Балаларны татар халкының мәдәнияте,гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре һәм бизәкләре белән таныштыру.<br>**Бурычлар:**<br>1)Хәзерге һәм элекке за-манда кулланылган әй- | Нәфасәти-эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3 | **Ашъяулык бизәү**<br>Квадратның читләрен һәм почмакларын милли орнаментлар белән бизәргә өйрәтү.Кайчы белән эшләү күнекмәләрен камилләштерү.Төс тоемлауны үстерү.<br><br>• Санның нәтиҗәсе предметлар арасындагы арага бәйле булмавын күрсәтү.<br>• 4-5 предметның биеклеген чагыштыра , үсү, кимү тәртибендә тезә һәм чагыштыру нәтиҗәләрен биек, тәбәнәгерәк, иң тәбәнәге, | **Йомгаклау чарасы:**“Карга боткасы” үткәрү.<br>Әңгәмә: “Татар милли ризыклары”, “Татар халык киемнәре”, “Милли уеннар”, “Милли бизәкләр”<br>Дид.уен: “Хатаны тап”, “Серле чәчәк”, “Парын тап”,“Нинди төстә”<br>Хәр.уен: “Очкычлар”, |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | берләр турындагы белемнәрне ныгыту.<br>2)Кабул итүләрен, фикерләүләрен, хәтерләрен, сүзлек байлыгын үстерү.<br>3)Татар халкынын әйберләренә карата кызыксыну тәрбияләү. | Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№2<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | биегерәк, иң биеге сүзләре белән билгеләүдә күнектерү.<br>• Геометрик фигураларны таный , атый белүдә күнектерү.(куб, шар)<br><br>**Халкыбызның мирасы белән кызыксыну**<br>Татар халкының декоратив кулланма сәнгать үрнәкләре белән таныштыру.Әбибабайларыбыз иҗат иткән әйберләргә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>**Озын күлмәк кигән кыз**<br>Балаларны татар костюмы төсләре,матурлыгы белән таныштыру. Рәсем аша озын киемле кеше образын гәүдәләндерергә өйрәтү.Нәфасәти кабул итүне үстерү.<br><br>**Аш вакыты**<br>Балаларның рәсемнәр аша милли ризыклар турында белемнәрен киңәйту.Чисталык,пөхтәлек тәрбияләү.Күзаллауларын үстерү. | “Тычканнар”,”Шалтыравык”**УМК,** “Мин сикерәм,син кул чәбәклә”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Матур уен”(тат. хал.уены), “Чума үрдәк,чума каз”(тат хал.уены)<br>С.рольле уен: «Без балалар бакчасында”, “Өй-өй”, “Кунак чакырдык”, “Без урамга чыгабыз”<br>Матур әдәбият: **УМК** Татар халык әкиятләре“Тавык,тычкан һәм көртлек”,“Ике кыз” “Гөлчәчәк” ,“Торна белән төлке”( тат.хал.әкият)<br>Бармак уены: “Бармакларны киендерәбез”. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **4 атна 20-24 март**<br><br>**Тема:**Язгы эшләр, тәҗрибәләр.<br>**Максат:**Бүлмә гөлләре,яшелчәләр турында күзаллауларын тирәнәйтү.<br>**Бурычлар:**<br>1.Тәҗрибә эшләре уздырганда,табигатьне сакларга кирәклеген төшендерү.<br>2.Хезмәт тәрбиясе аша экологик белемнәрен арттыру,сүзлек запасын баету..<br>3.Әйләнә-тирәдәге үзгәрешләр белән кызыксыну теләге тәрбияләү. | Нәфасәти- эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>**(УМК)**<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4 | **Тузганаклар**<br>Ярымкүләмле аппликацияләр әзерләргә өйрәтү.Тузганак үсемлеген дөрес итеп биткә урнаштыру,төсләрне аеру һәм дөрес атау.Балаларның әйләнә-тирә табигатьне нәфасәти кабул итүләрен үстерү.<br><br>• Санның нәтиҗәсе предметлар арасындагы арага бәйле булмавы турындагы күзаллауларын ныгыту (5 эчендә)<br>• Цилиндрны шар белән чагыштыруга нигезләнеп Цилиндр белән таныштыру<br>Күрсәтелгән юнәлеш буенча хәрәкәт итүдә күнектерү.<br><br>**Урман күлендә.УМК картинасы буенча сөйләшү.**<br>Балаларның [с],[з],[у],[ш] авазларын дөрес әйтүләрен ныгыту, [ж] авазының артикуляциясен исләренә төшерү; бу авазны сүзләрдә, фразаларда әйтүдә күнектерү; язның төп билгеләре, айлары, табигать күренешләре турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның сүзлек запасын киңәйтү; балаларның кызыксынуын, ишетү игътибарын, хәтерен, логик фикерләвен, вак моторикасын үстерү; балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.<br><br>**Язгы җыр**<br>Рәсемдә язгы хисләрне сүрәтләргә өйрәтү.Сүрәтне кәгазь битенә оста итеп ур- | **Йомгаклау чарасы:**Тәрәз төбендә-яшел бакча.<br>Әңгәмә: “Бакчадагы язгы эшләр”, “Тәрәз төбем гөлбакча”, “Суган утыртабыз”, “Чәчәк чәчәбез”<br>Дид.уен: “Хатаны тап”, “Сабаклар һәм тамырлар”, “Мин башлыйм,син әйт”,“Нинди яшелчә”<br>Хәр.уен: “Иң җитез”, “Елга аша күпердән”,”Туплар”УМК, “Үзеңә пар тап”УМК<br>ЭМТЧ: “Кем көчле”(тат. хал. әкияте), “Батыр әтәч”(татар хал.әкияте)<br>С.рольле уен: «Чәчтарашта”, “Өй-өй”, “Шифаханә”, “Әниле-кызлы”<br>Матур әдәбият: УМК М.Фәйзуллина“Ике көрәк”, “Дәү әнием бакчачы”Х.Халиков “Карлыган мунча керә” В.Хайруллина<br>Бармак уены: “Бармак,бармак,кая булдың?”,<br>“В огороде мы гуляем”<br>Өстәл уены: “Пазл” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Танып белү үсеше<br>(танып белү)<br>№5 | наштыра белү осталыкларын үстерү. Буяулар белән ясарга күнектерү (пумаланы әйбәтләп юу, буяуны пумалага алу).<br><br>**Суган утырту**<br>Хезмәт итү теләге тәрбияләү.Үсемлекләр турында сөйләшү,аларга үсәр өчен һава,кояш,су,җылылык кирәклеген тәшендерү.Суган турында төшенчә бирү,аның кеше сәламәтлегенә файдасын аңлату. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **5 атна 27 - 31 март**<br>**Тема:** “Хәрәкәттә бәрәкәт”<br>**Максат:** Балаларның сәламәт яшәү рәвеше алып бару турындагы күзаллауларын формалаштыру; сәламәтлеккә кагылышлы сүзләр белән сүзлек байлыгын арттыру.<br>**Бурычлар:**<br>1.Балаларда ихтыяр көче,сабырлык,кыюлык,уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2.Танып белү һәм мөстәкийль фикерләү эшчәнлеген үстерү.<br>3.Үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга ,иптәшләре алдында җаваплылык хисе тоярга өйрәтү. | Нәфасәти-эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру)<br>№6<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№2 | **Ни телисең шуны кисеп-ябыштыр**<br>Өйрәнгән алымнарны кулланып композиция кисеп-ябыштыру күнекмәсе формалаштыру.Җилем белән чиста пөхтә эшләү күнекмәләрен ныгыту. Күзаллауны,төсне тоюны,иҗадилыкны үстерү.<br><br>Уен – ситуация: “Куянкайдан хат”<br>• 5 эчендә әйтелгән сан буенча хәрәкәтләр эшләп күрсәтергә өйрәтү<br>• Таныш геометрик фигураларны аера һәм атый белүдә күнектерү(түгәрәк, квадрат, өчпочмак, турыпочмак.)<br>• Тәүлек өлешләре турында күзаллауларын камилләштерү :иртә, кич, көн, төн.<br><br>**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтүдә мөстәкыйльлек**<br>Балаларны мөстәкыйль киенергә,үзеңне тәртиптә тотарга өйрәтү.Җыйнаксызлык,шапшаклык кебек сыйфатларга тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. | **Йомгаклау чарасы:**<br>Күңел ачу чарасы: “Без спорт белән дус”<br>Әңгәмә: “Ничек дөрес юынырга”, “Су каян килә?””Авырмыйм дисәң...”<br>“Су ни өчен кирәк?”<br>Дид.уен: “Ярый-ярамый”, “Урынын тап”, ,“Курчакны киендер”<br>Хәр.уен: “Божрага керт”, “Чыпчыклар һәм автомобиль”**УМК**,”Кояш һәм яңгыр”**УМК**, “Куяннар”<br>**ЭМТЧ**: “Аю янында урманда”, “Матур уен”(татар хал.уены)<br>С.рольле уен: «Савыт-саба юабыз”, “Шифаханә”, “Әниле-кызлы”, “Күлмәкләр юабыз”<br>Матур әдәбият:Җ.Тәрҗеманов “Йомшак су,йөгерек су” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Нәфасәти- эстетик үсеш (рәсем)<br>№6<br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | **Үз теләкләре буенча рәсемләү**<br>Балаларны рәсем эчтәлеген уйларга, фикерләэрен ахыргача житкерергә өйрәтү. Мөстәкыйльлек,ижадыйлык тәрбияләү**.**<br><br>**Суның әһәмияте**<br>Балаларның су турындагы белемнәрен ныгыту,аның чисталык нигезеикәнлегенә төшендерү.Сулыкларны пычратмаска,сакларга кирәклеген төшендерү. | М.Фәйзуллина "Чисталык сөябез", Г.Юнысова "Тешләр", Г.Гыйлманов "Чишмәгә бардык" **УМК** |
| **А<br>П<br>Р<br>Е<br>Л<br>Ь** | **"Күп беләсем килә!"** | **1 атна 3-7 апрель**<br><br>**Тема:** "Күңелле ноталар"(музыка атналыгы).<br>**Максат**:Балаларны музыкаль әсәрләрне кызыксынып тыңларга,музыка агышына туры килә торган хәрәкәтләр ясарга өйрәтү.<br>**Бурычлар:** | Нәфасәти-эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3 | **Чәй савытлары җыелмасы**<br>Балаларның савыт-саба әвәләп ясау күнекмәләрен ныгыту.Яңа эш алымына-куыш форма ясау өчен батырып кртүгә өйрәтү. Җыелма төшенчәсен аңлатып,бер төсле бизәк төшерүгә ирешү.<br><br>**Уен – ситуация: "Уен мәйданчыгы төзибез"**<br>• Санау нәтиҗәсенең предметларның прстранствода ничек урнашуына карамавын күрсәтү. | **Йомгаклау чарасы:**<br>Музыкаль кичә **:** "Күңелле ноталар"<br>Әңгәмә: "Нәрсәләр ул ноталар?", "Музыка уен кораллары", "Без җырларга яратабыз", "Күңелле көйләр"<br>Дид.уен:"Нәрсәдән ясалган?", "Кызумы-әкренме?",<br>"Кайсы уен |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1.Төрле характердагы музыка(бию көе,марш,бишек җыры) тыңлау һәм аңа җавап хисләре бирергә өйрәтү.<br>2.Балаларда җырлыйсы килү ттеләге уяту.<br>3.Балаларның хәтерен,кабул итү сәләтен үстерү. | Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№2<br><br>Нәфасәти- эстетик үсеш (рәсем)<br>№6<br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | • Шар һәм куб белән чагыштыруга нигезләнеп цилиндр белән таныштыруны дәвам итү<br>• Ерак-якын сүзләренең мәгънәсе турындагы күзаллауларын камилләштерү.<br>**“Бишек җырлары”**<br>Балаларны бишек җырлары белән таныш-тыруны дәвам итү.Бишек җырларындагы ихлас мөнәсәбәтне тоярга өйрәтү.<br><br>**Үз теләгең буенча рәсем ясау**<br>Балаларны рәсемнең эчтәлеген уйларга һәм уйлаганнарын ахыргача җиткерергә өйрәтү. Мөстәкыйльлек һәм иҗадыйлыкны үстерү.<br><br>**“Музыка уен кораллары”**<br>Балаларны музыка уен кораллары белән таныштыруны дәвам итү, атамаларын хәтердә калдыру;аларда уйнау теләге уяту.Музыка ритмын тоемлауны үстерү. | коралы?”,“Дәвам ит”<br>Хәр.уен: “Еракка ыргыт”, “Бөҗралар”,”Кошлар оча”**УМК,** “Тупны сетка аша ыргыт”**УМК ЭМТЧ**: “Түбәтәй”( тат хал.уены), “ Кәрия-Зәкәрия”(тат хал.җыры)<br>С.рольле уен: «Барабанчы”, “Курчак авырый”, “Оркестр”, “Гармунчы”<br>Матур әдәбият: **УМК** Б.Рәхмәт “Музыка”, “Курай” Р.Бәшәр, “Бииләр итек,читекләр” Ш.Галиев, “Әйлән-бәйлән”Р.Миңнуллин |
| | | **2 атна 10-14 апрель**<br><br>**Тема:**Сәлам,галәм!<br>**Максат**:Космонавтлар турында белемнәрен киңәйтү.<br>**Бурычлар:**<br>1.12 апрель-космонавтика көне һәм Юрий Гагарин беренче космонавт белән балаларны таныштыру.<br>2.Балаларда горурлык хисе, кыюлык, батырлык, җитезлек сыйфатлары тәрбияләү. | Нәфасәти- эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3 | **“Очкычлар югары оча”**<br>Балаларны предмет өлешләрен әвәләргә өйрәтүне дәвам итү(салон,канатлар,пилот кабинасы).Форма чамалау хисен,иҗади күзаллауларын,вак моториканы үстерү.Пөхтәлек тәрбияләү.<br><br>**Уен – ситуация: “Әкиятләр бәйрәменә сәяхәт”**<br>• 5 эчендә предметларның санын, сан тәртибен билгеләп санау күнекмәләрен ныгыту”Ничә?”,“Ничәнче?” сорауларына җавп бирергә өйрәтү.<br>• Предметларны зурлыгына карап | **Йомгаклау чарасы:**<br>**“**Космонавтика көне” рәсем күргәзмәсе.<br>Әңгәмә: “Без космонавт-лар”, “Космик ракета”, “Күктәниләр бар икән?”, “Космоска очам”<br>Дид.уен: “Транспрт төрләре”, “Геометрик фигуралар”, “Кызыклы сәгать?”,“Домино”<br>Хәр.уен: “Кем беренче?”, “Агач төбендә куяннар”,”Песи һәм |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 3.Төрле уеннар аша балаларда космос турында беренче, иң гади күзаллаулар формалаштыру. | Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>№1<br><br>Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (танып белү)<br>№5 | чагыштыра һәм кимү, үсү тәртибе буенча тезә, чагыштыру нәтиҗәләрен түбәндәге сүзләр белән билгели белүләрен үстерү: иң зур, кескенәрәк, тагын да кечкенәрәк, иң кечкенә, зурырак.<br>• Тәүлек өлешләренең тәртип буенча урнаштыра белүләрен үстерү.<br><br>**“Очучылар”**<br>Балаларның очкычның өлешләрен, зурлыгын, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, “у” сузык авазын әйтүдә күнектерүне дәвам итү;балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, танып белүләрен, кызыксынуын үстерү; төрле гаскәр төрләренә, очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хис-ләр тәрбияләү.<br><br>**“Ракета”**<br>Рәсемдә катлаулы булмаган сюжены житкерә белергә өйрәтү.Предметның төзелешен,өлешләренең формасын сүрәтли белүләрен ныгыту.Якыннарына җылы мөнәсәбәт тәрбияләү.<br><br>**Өлкәннәр хезмәте( косманавт)УМК картинасы буенча сөйләшү.**<br>Өлкәннәрнең хезмәте төрле булуын аңлату.Балаларга космос турында төшенчә бирү, һава транспорты турында сөйләшү,уйлау,фикерләү сәләтен үстерү. | тычканнар”**УМК ЭМТЧ**: “Өч кыз”(татар халык әкияте), “Ике ялкау”(татар хал.әкияте)<br>С.рольле уен: «Космонавтлар”, “Чәчтараш”, “Кибетче”<br>Матур әдәбият: Йолдыз“Сәләм,галәм!”, “Кояш елый”З.Гөмәрова, “Кояштагы тап” Ф.Яруллин<br>Бармак уены: “Бармаклар ял итә”.<br>Өстәл уены: “Лото” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **3 атна 17-21 апрель**<br>**Тема: “Янгын куркынычсызлыгы”**<br>**Максат:**балаларны махсус автотранспорт һәм аның функцияләре белән таныштыру.<br>**Бурычлар:**<br>1.махсус автотранспорт турында төшенчә бирү.<br>2.Чагыштыру сәләтен үстерү.<br>3.Балаларның үзләрен тоту культурасы күнекмәләрен формалаштыру. | Нәфасәти- эстетик үсеш (кисеп-ябыштыру)<br>№6 | **Үз теләгең буенча кисеп-ябыштыр**<br>Балаларда иҗадилык, күзаллаулык, мөстәкыйльлекне үстерүне дәвам итү. Материалларны пөхтә итеп кулланырга, әвә-ләү алымнарын ныгыту. | **Йомгаклау чарасы:**<br>“Уттан сак бул!” поделка<br>Әңгәмә: “Янгыннан саклан”, “Янгын сүндерү машинасы”, “Шырпы уенчык түгел”, “Кызыл әтәч”<br>Дид.уен: “Бу кайсы билге”, “Кызыклы шакмак”, “Домино”,“Транспорт төрләре”<br>Хәр.уен: “Төз ат”,”Йөгерегез” “Куяннар”,”Поезд”**УМК,** “Мин сикерәм,син кул чәбәклә”**УМК**<br>**ЭМТЧ**: “Исемен ата”(башкорт хал.уены), “Зур туп”(рус.хал.уены)<br>С.рольле уен: “Без юлда йорибез”,“Янгын сүндерәбез”, “Пожарныйлар”, “Шоферлар”<br>Матур әдәбият: **УМК** Әкият уку “Песи өе”, “Үрли дә үрли генә”Ә.Бикчәнтәева, Батулла“Шапшакларны бака ялый” |
| | | | Танып белү үсеше (математика) №3 | **Уен – ситуация “Җәнлекләр бездә кунакта”**<br>• Төрле формадагы ике төркем предметның тигезлеген, тигезсезлеген парлаштырып карау нәтиҗәсендә чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Геометрик фигураларны аера һәм атый белүләрен ныгыту: түгәрәк, квадрат, өчпочмак<br>• Ике предметны биеклегенә карап чагыштыра һәм нәтиҗәсен биек, тәбәнәк, биегерәк, тәбәнәгерәк сүзләре белән билгели белүдә күнектерү. | |
| | | | Сөйләм үсеше (сөйләм теле)<br>**(УМК)**<br>№2 | **Олылар хезмәте(янгын сүндерүче)**<br>Балаларны янгын сүндерүче,махсус автотранспорт һәм аның функцияләре белән таныштыру. Аның үзенә генә хас үзенчәлекләре, анда эшләүче кешеләрнең профессияләре турында төшенчәләр бирү.Әлеге хезмәткә кызыксыну уяту. | |
| | | | Нәфасәти-эстетик үсеш (рәсем)<br>№6 | **“Бу өйдә кем яши?”(“Песи өе” өкиятенә нигезләнү)**<br>Рәсемнең эчтәлеген уйларга , уйлаганна- | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **4 атна 24-28 апрель**<br><br>**Тема:** Без Тукай оныклары.<br>**Максат**:Балаларны телләренең төрлелеге белән таныштыру; безнең туган тел –татар теле икәнен балаларга төшенедерү.<br>**Бурычлар:**<br>1.Г.Тукай иҗатына һәм үз туган телеңнең матурлыгына соклану хисләре тәрбияләү.<br>2.Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.<br>3.Балаларның сөйләм телләренең камиллеген үстерү. | Танып белү үсеше (танып белү)<br>**УМК**<br><br>Нәфасәти- эстетик үсеш (әвәләү)<br>№4<br><br>Танып белү үсеше (математика)<br>№3<br><br>Сөйләм үсеше (сөйләм теле) | рын ахырга кадәр җиткерергә өйрәтү. Мөстәкыйльлек тәрбияләү.<br><br>**Күңелсезлекләрдән ничек сакланыр-га ?**<br>Балаларны өйдә , ишегалдында, урамда, суда урманда , юлда килеп чыгарга мөм-кин булган күңелсезлекләр һәм алардан саклану чаралары белән таныштыру; бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br><br>**“Бәрәннәр”**<br>Балаларны хайваннар белән таныштыруны дәвам итү.Аларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.Өлешләрне салмак тоташтырып сылау күнекмәсен ныгыту.Төсләр ярашуын сайлауа зәвыклылыкны үстерү.Г.Тукай иҗатына хөрмәт тәрбияләү.<br><br>• санның нәтиҗәсе әйбер сыйфатының билгеләреннән(размер,төс) тормаганлыгы турында күзаллауларын ныгыту;<br>• әйбернең зурлыгы(5кә кадәр)чагыштыруда ;кимү һәм күбәю тәртибендә тезүдә(иң зурысы,кечерәк,тагын да кечерәк,иң кечкенәсе) күнектерү,<br>• тирә-юньдә ориенлаша белү күнекмәләрен камилләштерү(алда-артта,уңда-сулда,өстә-аста). | **Йомгаклау чарасы:**<br>Г.Тукай туган көненә багышланган бәйрәм иртәсе<br>Әңгәмә: “Тукай әкиятләре”, “Кем ул Тукай”,”Тукай шигырьләре ”, “И туган тел, и матур тел”<br>Дид.уен: “Бу кайсы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
